КАТЛАУЛЫ ЭШ
парламентта 2024–2025 елларга бюджет проектын карадылар
> 2

ДАНИЯ ӘХМӘТОВА:
«Һәр баланы үз үсеше белән генә чагыштыру урынлы»
> 5

ТЫЙНАК РАФИС
Татарда мондый язучы булуын белергә кирәк
> 5

ӘКИЯТМЕ, ЧЫНБАРЛЫКМЫ?
Әтнә театрының «Ак пароход»ы уйга салды
> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 148 (28921) | Шимбә | 8 октябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

БЕРДӘН ДҮРТ ЯСАУ

Республикада 12шәр мең сум күләмендә үзара салым җыючы авыллар бар. Кемдер 200 сум акча бирмәс өчен дә җан тартышып торганда, авыл мәнфәгате өчен 12 мең сумын да кызганмаучылар барлыгы сокландыра, әлбәттә.

Кеше башыннан 5 мең сумга якын акча җыеп тапшыручылар да бар. Дөрес, сирәк кенә булса да, халык каршы булганлыктан, референдум узмаган авыллар да очрый.

Татарстанда үзара салым программасы турында ишетмәүче кеше юктыр, булса да, сирәктер. 2013 елдан халыктан җыелган салым акчасы дәүләт тарафыннан финанслана, ягъни халыктан җыелган бер сум дүрт сум булып әйләнеп кайта. Аның ярдәмендә республиканың башка программалары кереп җитә алмаган авыллар юллы булды, зират, һәйкәлләр төзекләндерелде, урамнар яктыртылды, спорт һәм балалар мәйданчыклары урнаштырылды, су проблемалары хәл ителде. Яхшы бит: җыелган акча читкә китми, бер сумга дүрт сум исәбеннән дәүләт субсидиясе алынып, авылда шактый зур эшләр башкарыла. Кыскасы, хезмәт нәтиҗәсе – күз алдында.

Узган ел Мөслим районының Әлмәт авылында гаиләдәге һәр кешедән 4800 сум исәбеннән җыйганнар. Йортта ике кеше яши дип уйласак, бер гаиләдән 10000 сумга якын акча чыга дигән сүз.

– Акчаны максатчан җыйдык. Авылдагы су составында тимер күп иде. Шунлыктан, халык белән уйлаштык та өстәмә су скважинасы казытырга булдык. Июньдә эшне башкарып та чыктык, – диде Әмәкәй авыл җирлеге башлыгы Илнара Шакирҗанова.

Әлмәт авылында халык аз яши. Нибары 43 кеше генә.

– Беркем дә каршы килмәде. Әти-әниләре өчен балалары түләүчеләр дә булды. Гомумән, минем җирлек халкы иң беренчеләрдән булып җыеп тапшыра акчаны. Мин үзем биш ел шушы вазыйфада. Ел да ике ай эчендә 100 процент җыеп тапшырабыз. Төрле суммалар җыйганыбыз булды. 1200–1700 сумга кадәр җыйган вакытлар да булды. Күптән түгел генә Өлкәннәр көне узды. Ул чакта да халык белән җыелышып, эшлисе эшләрне барладык. Һәм шул аралашулардан соң, быел Әмәкәйдән 1500 сум җыярга кирәк булыр, дип чамаладык, чөнки аларда су скважинасы казытырга уйлыйбыз. Әлмәттә 1200 сум булыр дип торабыз. Алдагы елларда да юлларны, урам утларын карадык, скважинаны коймаладык, ике су каланчасын әйләндереп алдык. Киләсе елда Әмәкәйдә су мәсьәләсен ерып чыга алсак, бик яхшы булыр иде.

Быел әлеге авылларда референдумнар ноябрь уртасында узачак.

– Үзегез беләсез, бу көннәрдә халыкның башын башка борчулар басты. Шуңа күрә быел күңелдә бераз шикләнү, шом булса да, яхшыга өметләнәбез, – диде Илнара Шакирҗанова.

4800 сум җыйган авылга бер гаҗәпләнсәк, кеше башыннан 12 мең сум җыйганына икеләтә шаккаттык. Анысы Кукмара районында булып чыкты. Биредә 8 һәм 13 кешелек ике авылда әнә шундый суммада акча җыйганнар. Җыелган акчага суларны һәм юлларны караганнар.

Район башлыгы урынбасары Равия Кәримуллина әйтүенчә, районда үзара салым акчасы бер дә җыелмый калган авыллар юк.

– Шул ук вакытта барлык кеше дә акча биреп бетермәгән авыллар да бар, ләкин андыйлар бик аз. Районыбызда берәр мең сумнан җыючы авыллар да шактый. Алар янгын куркынычсызлыгы буенча мичкәләр алып куйдылар, юлларны карадылар. Узган ел халыктан 25 млн сум акча җыелган иде. Республика акчасын кушкач, 121 млн сумнан артып китте. Юллар, күперләр, җәяүле юллары, зиратлар каралды, янгын гидрантлары урнаштырылды, су системалары яңартылды. Кайбер авылларда күзәтү камералары да куелды, – диде ул.

Менә шулай күпләп акча җыеп, юлларында су, ут, юл һәм башка проблемаларны хәл итәргә тырышып йөрүчеләр белән бергә, акча җыюны кирәксезгә санаганнар да бар.

– Үзара салым акчасы җыю мәсьәләсендә артыгын мактана алмыйбыз, – ди Биектау районы башлыгы урынбасары Әнәс Шакиров. – Авылларда яхшы җыялар аны. 80–90 процент була. Тик без Казанга якын район булгач, башкала янәшәсендәге авылларда җыю бик авыр. Халыкның күпчелеге теркәлгән булса да, шәһәрдә яши. Яки акча бирүне кирәксенми.

Быелгы вазгыятьтә референдумнар уздырылып, авылларда эшләр эшләнерме? Әлеге сорауны республиканың Муниципаль берәмлекләр советы ассоциациясенә юлладык.

– Быел да ноябрьдән башлап, җирлекләрдә референдумнар узачак. Илдәге вазгыятькә карамастан, халыктан җыелган акча үзара финансланып, авылларда уңайлыклар тудыру дәвам итәчәк, – дип җаваплады безгә ведомствода. – Шунысын искәртик: үзара салым ул бурыч түгел, ә авыл ихтыяҗларына өстәмә акча җыю мөмкинлеге генә. Ул референдум һәм тавыш бирү юлы белән халыкның бары тик үз ихтыяры белән генә җыела. Дәүләт ярдәме зур булуга карамастан, муниципаль берәмлекләрнең җирле бюджетларында әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җитмәскә мөмкин. Мондый шартларда җирле хакимиятләр үз җирлекләрендәге проблемаларны хәл итү өчен мөмкинлекләр эзли һәм өстәмә инструментлар җәлеп итә. 2013 елдан башлап үзара салым акчасы җыю-җыймау турындагы карар референдумнар һәм җыеннар аша хәл ителә. Татарстан исә мондый мөмкинлектән актив файдалана.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сан

- 2013–2022 елларда Татарстан бюджетыннан үзара финанслау өчен **7 млрд 812,9 млн сум** акча бүлеп бирелгән. Быел бу сан 1352,1 миллион сумны тәшкил итә.
- 2013 елдан алып 2022 елның беренче яртыеллыгына кадәр 1972,59 млн сум үзара салым акчасы җыелган.
- 2015 елда – халыкның 87,9 проценты, 2016 елда – 86,6, 2017 елда – 86,9, 2018 елда – 82, 2019 елда – 82,9, 2020 елда – 81,9, 2021 елда 91,3 проценты үзара салым акчасы җыюда катнашкан.
- Узган ел үзара салым буенча җыеннар 890 авылда узды.

Каникул гамәлдә

Россия Президенты Владимир Путин мобилизациягә эләккән кешеләр һәм аларның гаилә әгъзалары өчен кредит каникулы турындагы законга кул куйды. Әлеге закон кулланучылар кредитлары һәм заемнарына, шул исәптән, ипотека һәм кредит карталары буенча түләүләргә кагыла. Рәсми документтан күренгәнчә, әлеге мөмкинлектән файдалану өчен, 2023 елның 31 декабренә кадәр кредит алган урынга – банкка, микрофинанс оешмасына һ.б.ларга мөрәҗәгать итәргә кирәк. Гариза белән бергә махсус операциядә катнашуны раслаган документны да тапшырырга кирәк. Хәрби хезмәткәр һәлак булса яки I группа инвалидлык алса, аның һәм гаилә әгъзаларының кредитлары һәм заемнары да юкка чыгарыла.

Бәяләр арта

Татарстанда соңгы атнада кайбер азык-төлек продуктларына бәяләр арткан. «Татарстанстат» мәгълүматларына караганда, 26 сентябрьдән 3 октябрьгә кадәр аралыкта республикада суган, бәрәңге, кәбестә һәм кишернең хакы күтәрелгән.

Бәрәңгегә бәя, 3,75 процентка артып, килосы 24,38 сумга җиткән. Кәбестәнең бәясе 2,18 процентка арткан. Хәзер аның килосы – 16,81 сум. Кишернең килосы – 25,33 сумга, суганныкы 26,21 сумга кадәр күтәрелгән. Ә чөгендер бәясе, 2,44 процентка кимеп, 24,97 сумны тәшкил итә.

Йортлар буш тормый

Соңгы 15 елда Татарстанда торак тапшыру күләме ике тапкыр арткан. Бу хакта республиканың төзелеш, архитектура һәм ТКХ министры Марат Айзатуллин «100% Татарстан» форумында хәбәр итте. «2022 ел азагына Татарстанда өч млн квадрат метрдан артык торак кулланылышка тапшырылыр дип көтелә», – диде ул.

Хәзерге вакытта Татарстанда кулланылышка тапшырылган торак күләме 2,5 млн квадрат метрны тәшкил итә. Бу – еллык планның 91 проценты.

Ярминкәләр гөрли

Татарстанда көзге ярминкәләр дәвам итә. Алар 24 декабрьгә кадәр һәр шимбә саен оештырылачак. Казанда – сәүдә барлыгы 14, Чаллы һәм Яшел Үзәндә – икешәр, Түбән Камада өч мәйданчыкта гөрләячәк. Ярминкәләр шулай ук республиканың 26 районында да узачак. Фермерлар шәһәр халкын чагыштырмача арзан бәядән сыйфатлы азык-төлек белән тәэмин итәчәк. Ярминкәләрдә ит, яшелчә, башка продукция, шулай ук хуҗалык кирәк-яраклары сатып алырга мөмкин.

Сүз уңаеннан, 10 сентябрь – 1 октябрь аралыгында оештырылган 4 ярминкәгә барлыгы 406,7 млн сумлык продукция (4,5 тонна яшелчә, шул исәптән 3,2 тонна бәрәңге, 62,4 тонна сөт, 429,3 тонна ит) китерелгән.

Борчыган мәсьәлә

Ышанмаска кирәк

Россиядә алдалауның яңа төрен уйлап тапканнар. Мошенниклар үзләрен Үзәк банк хезмәткәрләре дип таныштыра икән. Моның өчен ялган таныклык күрсәтәләр. Бу хакта Үзәк банкның «Телеграм» каналында хәбәр ителә.

Безнең инде күп тапкыр банк хезмәткәре булып шалтыратучылар белән очрашканыбыз бар. Аларның бик оста эшләгәнен дә беләбез. Бу хакта күп тапкыр кисәтсәк тә, алданучылар саны кимеми. Яңа төр алдалауны уйлап чыгаручылар кешегә шалтыратып, аның исәп-хисап счетында ниндидер операция башкарылуын хәбәр итәләр. Янәсе, алар моны булдырмый калырга ярдәм итәчәкләр. Ышандыру өчен мессенджерларда ясалма таныклыкларын җибәрәләр. Ул таныклыкта хәтта шул банкта хәзерге вакытта эшләүче хезмәткәрнең исем-фамилиясе дә язылган булырга мөмкин. Алдакчылар бу мәгълүматны банк сайтыннан ала икән.

Кешене тәмам ышандырып бетергәч, алар йә аның исеменә кредит рәсмиләштерәләр, йә инде исәп-хисап счетындагы акчасын үзләштерәләр. Үзәк банк исә физик затлар белән эшләми һәм берәүнең дә исәп-хисап счетларын алып бармый. Шулай ук банк хезмәткәрләре смс хәбәрләр аша беркайчан да үзләренең документ нөсхәләрен кешегә таратмый.

– Әгәр сезгә мошенниклар шалтыратса, шунда ук сөйләшүне өзеп, бу номерны «кара исемлек»кә кертеп куегыз. Әгәр инде банкта яки картагызда акчагыз бар икән, бу очракта үзегез шалтыратыгыз. Банк номерларын аның рәсми сайтында яки картагызның икенче ягыннан карап була, – дип киңәш бирә Үзәк банк.

Хәзерге вакытта Дәүләт Думасы депутатлары россиялеләрнең банк карталарыннан акча урлауга каршы юнәлтелгән закон проектын өйрәнә. Әлеге проект кабул ителгән очракта, Эчке эшләр министрлыгы Үзәк банктан клиент рөхсәтеннән башка күчерелгән акча турында мәгълүмат ала алачак. Ягъни Үзәк банк клиентларының рөхсәтеннән башка да аларның исәп-хисап счетыннан акча күчерү һәм күчерергә җыену турында хәбәрне Эчке эшләр министрлыгына җибәрәчәк. Ничек итеп эшләячәкләре хакында ике арада төзелгән килешүдә күрсәтеләчәк. Банклар шикле реквизитларга акча күчерүне 2 көнгә туктатып та тора алачак.

– Кешеләргә мошенниклар көненә әллә ничә мәртәбә шалтыраталар. Халыкның банктагы акчасын урларга теләүчеләрнең эзләренә төшәргә кирәк, – ди Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володин. Аның сүзләренә караганда, ел башыннан, банк карталарын кулланып, 72 мең җинаять кылынган.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сүзгә-сүз

Александр ЛОМАКИН, Россия төзелеш һәм ТКХ министрының беренче урынбасары:

Бүгенге икътисади вазгыятьтә төзелеш темпларының кимүенә юл куймаска кирәк. Төзелеш Россия икътисадының көчле өлкәсе булып тора. Шуңа да төзелеш комплексына ярдәм итү – дәүләтнең мөһим бурычларының берсе. Төзелештә билгеләнгән барлык ниятләрне вакытында гамәлгә ашырырга кирәк.

(«Татар-информ»)

РОССИЯДӘ – АКЧА САКЛАУ

Акчаны банкта сакларгамы, өйдәме? Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге мәгълүматларына караганда, соңгы елларда акчаларын банкка ышанып тапшыручылар санының кимүе күзәтелә.



Реклама 16+

Сөенечле хәбәр!

2022 елның 3–13 октябрь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 жомга саны

Ташламалы бәя 444 сум 54 тиен

гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга

Ташламалы бәя 980 сум 10 тиен

гадәти бәясе – ~~1143 сум 96 тиен~~

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Атом сугышы: җиңүче булмаячак

Дөнья глобаль атом сугышына кереп китүдән берничә адымда гына туктап калган Кариб кризисына шушы көннәрдә 60 ел тула. Бүгенге кайбер сәясәтчеләр ул вакытны, ул кризисны җентекләп өйрәнде микән? Ихтимал, юктыр. Тарихның төп сабагы – аннан бер сабак та алынмау, дип юкка әйтмиләр бит. Аерым вазыйфаи затлар бүгенге катлаулы халыкара вазгыятьне, проблемаларны атом көчәге аша, аны кулланып хәл итәргә өндәмәс иде…

Кешелеккә ике Бөтендөнья сугышы, миллионлаган корбаннар китергән, тарихта калып барган XX гасыр тагын шул ягы белән үзенчәлекле һәм куркыныч: шул йөз ел эчендә Җирдә, чүп өстенә чүмәлә, дигәндәй, күпләп юк итү коралларының да берничә төре яралды. Андый хәл нәрсәне аңлатты соң? Ул моңарчы да канлы бәрелешләрсез яши белмәгән кешелекнең, аягын салындырып, дары мичкәсе өстенә менеп утыруы, инде аннан төшмәячәге, акылын тәмам югалтуы булды кебек. Хәер, кешелек дисәк тә, сугыш теләмәгән гади халыкны акылын югалтучылар рәтенә кертү бик үк дөрес булмас. Адәми затларның сугышып, үз ишләренә утлы коралдан атуы, берәмләп, «санап» кына бер-берен үтерүе мин-минлекле сәясәтчеләргә, кешене бөҗәктән артык күрмәгән аерым дәүләт җитәкчеләренә аз тоелган булса кирәк. Гади халык түгел, нәкъ шул адәми затлар кешене чебен урынына кырырга сәләтле корал хакында хыялланган, хыялын тормышка да ашырган булып чыга. Химик корал, бактериологик корал һәм дәһшәтле атом-төш коралы – һәммәсе дә үткән XX гасыр «казаныш»лары. Араларында иң әшәке саналганы – атом бомбасы – уйлап табу, ясый башлауга күп вакыт узмаса да, планетаны берничә тапкыр яшәү белән үлем арасында калдырырга өлгерде дә кебек. Шуның берсе нәкъ без әйткән кризис – 1962 елның октябрендә булды.

Ни өчен Кариб кризисы? Чөнки ул вакыйгалар үзәгендә торган ил – Куба урнашкан утраулар Кариб диңгезенә карый. Сәяси һәм хәрби кризис Никита Хрущев җитәкләгән совет хөкүмәте шул тарафка – «Азатлык утравы»на, империализм үзәге саналган АКШның нәкъ борын төбенә атом бомбалы баллистик ракеталар урнаштыра башлагач кабынып китә. СССР ни өчен ул эшкә барган? Беренчедән, океан артына яшеренеп, тыныч кына яшәп яткан янкиларның котын алу өчен. Икенчедән, бер ел элек кенә Америка, шундый типтагы ракеталарын Советлар Союзы биләмәләренә ярыйсы якын тарафка – Төркия территориясенә китереп утырткан була. Җир читендәге Кубага ракеталар ташу, урнаштыру АКШ администрациясенә, ягъни «Чемберлен»га җавап рәвешендә оештырыла. «Анадырь» операциясе шул дәрәҗәдә яшерен кимәлдә үтәлә, хәтта ракета төягән кораб капитаннары да баштагы мәлне кая таба баруларын, кемгә нәрсә илтүләрен белми. Ләкин ракеталар тиешле урынга җиткерелеп, позицияләргә куела башлагач, американнарның һава разведкасы эшне сизеп ала. Коточкыч гауга куба. Янаулар, куркытулар башлана. Куба блокадага алына. Һәр ике як та үзендә булган барлык ракеталарны, стратегик бомбовозларны сугышчан әзерлеккә китерә. Ике як та ай буе атом сугышы көтеп, ул менә-менә кабына, дип яши.

Сугышчан әзерлек димәктән, шунысы кызык һәм кызганыч: СССР җитәкчесе бер ел элек кенә: «Без ракеталарны сосиска ясаган кебек, конвейерда гына ясыйбыз, аларның бездә чуты юк», – дип шапырынса да, ул вакытта ил баллистик ракеталар буенча да, стратегик авиациягә караган очкычлар саны буенча АКШтан нык калыша. Ә инде боеголовкалар, ягъни атом-төш коралы күләменә килгәндә, американнар арсеналындагы 6 мең бомбага каршы Советлар Союзының ул елда нибары 300ләп кенә шундый ук коралы була. Русча «блеф» дип аталган алым, күрүебезчә, ул вакытта да яхшы кулланылган. Чөнки чит территориядәге коралның чутын алып, санап чыгу ул вакытта да мөмкин эш булмый, бүген дә шулайрак.

Хронологиягә артык бирелмичә генә, дөньяны калтыраткан ул кризисның 38 көн дигәндә гарасатсыз гына тәмамлануын, СССРның – Кубадан, АКШның Төркиядән ракеталарын, ракетага атланган атом-төш коралын чыгаруын искәртик. «Салкын сугыш» дип аталган ашкынып кораллану, бер-береңә ышанмау чорында Никита Хрущев белән Джон Кеннеди куркыныч вазгыятьне зурга җибәрмичә, килешүгә ирешә алган…

Бүгенге вазгыять бераз башка – океан артындагы ил белән турыдан-туры аркан тартышу, низаг юк. Мөнәсәбәтләр ачыклау Европа кыйтгасына урнашкан дәүләт – Украина, андагы хәрби конфликт аша бара. АКШ Россия белән чиктәш илгә күпләп корал ташый, матди һәм финанс ярдәме күрсәтә. Андый гамәлдә Көнбатыш Европаның аерым илләре дә бик актив. Ягъни, бездәге сәясәтчеләр сүзе белән әйткәндә, алар, җыйнаулашып, янган учакка коры утын өстәп тора. Һәм менә шул гамәлгә җавап рәвешендә булса кирәк, узган атнаны, конфликт барышында беренче тапкыр, Украинага каршы кече егәрлектәге атом коралы куллану тәкъдиме яңгырады. Көтмәгәндә, уйламаганда. Мондый тәкъдим белән, белүебезчә, Чечня җитәкчесе Рамзан Кадыйров чыкты. Бер атна үтүгә, каршы яктан тавыш ишетелде. Украина президенты Зеленский Көнбатышны Россиягә каршы превентив (кисәтүче) атом һөҗүме ясарга котыртты. Шунысы куанычлы: Кадыйровка да, Зеленскийга да теләктәшләр табылмады кебек. Ә инде, авызыгыздан җил алсын, диючеләр хәтсез булды.

Атом-төш коралы белән уйнауның Көнбатышка да, Россиягә дә стратегик өстенлек, уңыш китермәячәген аңлатып үтик. Бүгенге тактик атом коралы, егәре ягыннан, белгечләр әйтүенчә, Икенче Бөтендөнья сугышы азагында Хиросимага ташланган бомбадан аз калыша. Ә анысы, белгәнебезчә, бер мизгел эчендә 80 мең кешенең башына җиткән. Тагын 120 мең чамасы халык радиация китергән чирләрдән үлә. Шәһәр хәрабәләргә әйләнә. Атом бомбасы кешене хәрбиләргә һәм хәрби булмаганнарга аермый. Балаларны, хатын-кызларны аямау аны кулланган илне шунда ук бөтен кешелекнең дошманы итәчәген билгелик. Экологик гарасат, флора, фауна – нинди тереклек бар, барысының да юкка чыгасын аңлатып тору да артык. Җилнең киләсе тәүлектә радиоактив болытны кайсы якка куасын да алдан төгәл белеп булмый. Каршы як гаскәрнең сугышчан рухын сындыру (деморализация) дигәндә дә эш барып чыкмаска мөмкин. Чөнки Хиросимадан аермалы буларак, атом коралының ни-нәрсә икәне хәзер бар кешегә дә мәгълүм. Каршы якның ни рәвешле, нинди егәрлек белән җавап бирәсе дә билгесез. Ни генә дисәк, кайсы гына яктан килсәк тә, атом сугышында җиңүче була алмый.

ТР Дәүләт Советында

БИЛГЕСЕЗЛЕКНЕ ФАРАЗЛАУ

tatarstan.ru

Кичә парламентта 2023 елга һәм 2024–2025 еллар план чорына бюджет турында закон проектын тикшерделәр. Иртәгәге көн ничек буласын белмәгәндә, бюджет фаразлау, аны «кеше кыяфәтенә» кертү – әлбәттә, бик кыен эш. Моны парламент тыңлауларында чыгыш ясаган хөкүмәт әһелләре дә, депутатлар да яшермәде.

Утырышны алып баручы – Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты рәисе Леонид Якунин да, беренче нотыкчы – Премьер-министр урынбасары, икътисад министры Мидхәт Шаһиәхмәтов та билгесезлекне фаразлауның ни дәрәҗәдә четерекле икәнен әйтеп сүз башладылар. Өсте-өстенә салынып килгән санкцияләрнең һәр тармакка тискәре йогынты ясавын да яшермәделәр. Инде нишләргә соң?

Нишлисең, «бетәбез!» дип кул кушырып утырып булмый. Мидхәт әфәнде әйтүенчә, оператив штаб белән берлектә әледән-әле утырышлар уздырып, авырлыктан чыгуның яңадан-яңа юлларын эзлиләр икән. Система хасил итүче предприятиеләргә игътибар аеруча зур һәм ашыгыч чаралар федераль коллегалар белән бергә эшләнә. Шул ук вакытта, Татарстан икътисадында өлеше 26,1 процент булган кече һәм урта эшмәкәрлеккә дә дәүләт ярдәме кимемәячәк. Нәтиҗәдә, 2023 һәм 2024–2025 елларга җитештерү үсеше 2–3 процент чамасы булыр, дип фаразлана.

Төп капиталга инвестицияләр кертү буенча да эш яхшы гына бара, диделәр. Бу өлкә буенча без алдынгылардан саналабыз икән.

Министр чыгышыннан соң, аңа депутатлардан сораулар шактый яуды.

Кичә Көнбатыш һәм Европа илләренең тагын бер санкциясе билгеле булды. «Россиягә каршы як» дип әйтик инде, безнең нефть бәясенең иң югары чиген билгеләде. Ә без, җавап итеп, ниләр эшләргә җыенабыз? Хәерчелеккә каршы ничек көрәшергә? Уртача хезмәт хакы күләме буенча Татарстанның арттарак калып баруы турында да сүз кузгатты депутатлар.

Мидхәт әфәнде, әлбәттә инде, һәр очрак өчен тәгаен генә ниләр эшләнүе турында бармак бөгеп санамады һәм бу мөмкин эш тә түгел. Вазгыять еш үзгәреп тора. Шуңа күрә җаваплар, нигездә, «эш алып барыла» дигәнгә кайтып калды.

Инде Татарстанның алдагы елларга бюджет проектына килсәк, финанс министры Радик Гайзатуллин әйтүенчә, бөтен бюджет йөкләмәләре үтәләчәк. Табышка салым керемнәрен бәяләгәндә, быелның узган чорындагы салым җыю динамикасы файдаланылган.

Ә ул начар түгел иде. Нәтиҗәдә, 2023 елда табышка салым 103,1 млрд сум булыр дип көтелә. Ә берләштерелгән бюджетның салым булмаган керемнәре – 11,2 млрд сум, республика бюджетыныкы 6,1 млрд сум күләмендә булыр, дип планлаштырыла. Киләсе елга федераль казнадан да 51,9 млрд сум килүен көтәбез. Шөкер, болары – кайтарылмый торган керемнәр.

Әлеге саннар халыкка әллә ни мәгълүмат бирмидер дә, әлбәттә. Әмма аларның кимемәве күңелне тынычландыргандай итә. Уртача хезмәт хакының артуы көтелү дә – «күңелле фараз».

Социаль сәясәт тармагы турында да бер-ике сүз әйтик әле. Бу өлкәгә берләштерелгән бюджет чыгымнарының 57,7 млрд сумы, республика бюджеты буенча 57,5 млрд сум бирелер дип фаразлана. Әмма әлеге күләмнәрдә барлык социаль пособиеләр һәм түләүләр инфляция зурлыгында индексацияләнгән. Бу шактый киеренке заманда күңелсез нәрсәләр язып, хезмәт ияләренең күңелен төшерәсе килми. Хөкүмәт әһелләре дә чама белән генә чыгышлар ясадылар. Мәҗбүри медицина иминияте фонды җитәкчесе Алсу Мифтахова да һәрвакыттагыча сабыр гына сөйләгән иде. Әмма депутатлар арасыннан махсус хәрби операциягә бәйле чыгымнар, фондның мәшәкате тагын да артачагы турында сүз кузгатучы табылды. Яралылар, гарипләнгәннәр сезгә киләчәк, диделәр. Баксаң, ул мәсьәлә турында сөйләшүләр булмаган әле.

Парламент тыңлаулары ахырында Премьер-министр Алексей Песошин система хасил итүче предприятиеләргә заказлар артуын әйткән иде. Без моны хәрби операциягә бәйле дип фаразладык инде. Алексей Валерьевич та үзен шактый тыныч тотты. Вазгыятьнең ничек үзгәрәсен анык кына билмибез, дисә дә, һәр тармакка ярдәм күрсәтеләсен, бюджет йөкләмәләре үтәләсен һәм мая, ягъни запас барлыгын әйтеп, күңелне тынычландырды. Хәлләр «теләгән идек кара кашлыны, тоттырдылар ялтыр башлыны»га әйләнеп калмаса ярый инде.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Көнчыгышка борыласы

Дөнья сәясәтенең үзәге шул якларга күчә. «Бердәм Россия» партиясе Генераль советының Халыкара хезмәттәшлек һәм чит илдәге ватандашларга ярдәм буенча комиссиясе утырышында Россия төбәкләренең Азия – Тын океан илләре белән хезмәттәшлеге турында сөйләштеләр. Анда Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да үз фикерләрен җиткерде.

Утырышта Россиянең тышкы эшләр министры, әлеге комиссиянең рәисе Сергей Лавров бүгенге шартларда Азия илләре белән икътисади, парламентара һәм партияара хезмәттәшлекнең мөһимлеген әйтте. «Дөнья сәясәтенең үзәге Евроатлантикадан Евразиягә һәм Азия – Тын океан төбәгенә күчә», – диде ул.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, республиканың Азия – Тын океан илләре белән хезмәттәшлеге турында сөйләгәндә, Кытай белән элемтәләргә аерым тукталды. «Кытай Халык Республикасы безнең белән сәүдә-икътисади, фәнни-техник, мәгариф, мәдәни һәм гуманитар өлкәләрдә күптән хезмәттәшлек итә. 5 елдан артык Кытай Татарстанның төп тышкы сәүдә партнерлары булган ун ил арасына керә. Гуманитар юнәлештәге хезмәттәшлек ныгый. Татарстан югары уку йортларында бу илдән 1728 студент белем ала, аларның саны арта бара. 2014 елдан башлап Пекинда Россиянең сәүдә вәкиллеге составында Татарстанның Сәүдә-икътисад вәкиле, ә 2016 елдан Казанда Кытайның Генераль консуллыгы эшли», – диде Фәрит Мөхәммәтшин. Моннан тыш Татарстан «Волга – Янцзы» проектын тормышка ашыруда да катнаша. Ул Россиянең Идел буе төбәкләре һәм Кытайның кайбер провинцияләре арасындагы элемтәләрне ныгытуны күздә тота.

«Бердәм Россия» белән Кытай Коммунистлар партиясе арасындагы хезмәттәшлек турында сөйләгәндә, Фәрит Мөхәммәтшин соңгы биш елда Татарстанга бу илдән зур кунаклар килгәнен искә алды. Казанда Россия – Кытай форумы һәм «Бердәм Россия» белән Кытай Коммунистлар партиясенең уртак утырышы узды.

Әмма хезмәттәшлек итүче Азия – Тын океан төбәге илләре Кытай белән генә чикләнми. Соңгы елларда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм республика делегацияләре Япония, Корея, Малайзия, Сингапур, Вьетнам, Мьянмага сәфәр кылды. Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, бу илләр дә безнең белән кызыксына. Дәүләт Советы Рәисе фикеренчә, алар белән муниципалитетара элемтәләрне дә барларга кирәк.

Үзебезнең үрнәктә

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, республика Волейбол федерациясе президенты Фәрит Мөхәммәтшин хатын-кыз ветераннар командасы – волейбол буенча 50 яшьтән өлкәннәр командалары арасында Россия чемпионаты җиңүчеләре белән очрашты. Парламент җитәкчесе, волейболчыларны котлап, аларга Россия Кубогы финал уеннарында да җиңү теләде.

Әлеге спорт төре буенча ветераннар командаларының бөтенроссия ярышлары Анапа шәһәренең Витязево бистәсендә 24 сентябрьдән 2 октябрьгә кадәр узды. Безнең хатын-кыз волейболчыларыбыз, көндәшләрен җиңеп, 160 команда арасында иң көчлеләр булып танылды.

«Шушындый чемпионнар ярдәмендә Татарстанның абруе саклана да инде, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Волейбол иң киң таралган спорт төренә әйләнде. Аны предприятие эшчеләре дә, муниципалитетлар вәкилләре дә үз итә. Без Мәктәп волейбол лигасын үткәрү тәкъдиме белән дә чыктык. Болар барысы да милләт саулыгы өчен эшләнә. Үзебезнең үрнәктә яшь буынны тәрбиялик».

Очрашуда Россия чемпионаты җиңүчеләре Фәрит Мөхәммәтшинга култамгалары куелган алтын туп бүләк иттеләр. Фәрит Мөхәммәтшин исә аларга Татарстан Волейбол федерациясе президентының рәхмәт хатларын тапшырды.

УРМАН ЙОКЛАМЫЙ

Табигать сагында

Көзен утырткан агач нык була. Татарстан урманчылары әнә шулай ди. Республика урманнарында агач утырту эшләре дәвам итә. «Урманнарны саклыйк» бөтенроссия акциясе кысасында Татарстанда 2 миллион данәдән артык агач утыртылачак. Урманнар ни хәлдә? Без бу хакта урманчылар белән сөйләштек.

tatarstan.ru

– Республикада урманнарны яңарту эшләре ел дәвамында башкарыла. Агач утырту акцияләре дә үткәрелеп тора. Без бу эшне язын һәм көзен эшлибез. Урманчы буларак шуны әйтә алам: көзен утырткан агачның үсеп китү мөмкинлеге зур. Алар тизрәк тернәкләнә, – ди Казан шәһәр яны урманчылыгы җитәкчесе Илнур Кәшәфиев. – Безнең якларда нарат, Европа чыршысы, себер карагае, вак яфраклы юкә һәм миләш агачлары яхшы үсә. Шуңа күрә утыртканда аларны сайлыйбыз.

Урманчылар сүзләренә караганда, Татарстанда утырту өчен чимал җитәрлек. Республиканың 51 питомнигында һәм Саба селекция-орлыкчылык үзәгендә ел саен 12 миллион данә кәлшә үстерелә.

Балык Бистәсе районында урнашкан Кызыл Йолдыз урманчылыгы җитәкчесе Нияз Таҗмиев әйтүенчә, урманчылар киләсе ел өчен орлык әзерли. Бу көннәрдә имән чикләвеге җыйганнар. Балык Бистәсе районы урманнарында аның уңышы сөенерлек түгел икән. Шуңа алар нарат, чыршы күркәләрен дә җыялар. Киләсе елда шушы орлыкларны утыртып, үсенте алмакчылар.

– Урманнарны тәртипкә китердек. Күп тапкыр өмәләр ясап чистарттык. Көздән үк җирләрне эшкәртеп әзерләп куябыз. Яз көне утырткан агачларны барлап чыгабыз. Әгәр алар үсеп китмәгән икән, яңаларына алмаштырабыз, – ди Нияз Таҗмиев. – Без инде киләсе елда янгын куркынычсызлыгына әзерлекне башладык. Урман буйларын көздән махсус сукалатып куябыз. Алдан хәстәрен күрсәк, үзебез өчен дә, урманнарны саклау өчен дә уңай булачак.

Татарстан Урман хуҗалыгы министрлыгының урманнарны яңарту һәм үрчетү бүлеге җитәкчесе Тимур Галиев сүзләренә караганда, Әгерҗе, Биләр, Яшел Үзән районнарында имән чикләвеген җыялар икән әле.

– Безгә урман барлыкка китерүче төп токымнардан барлыгы 11,5 тонна орлык әзерләргә кирәк. Әлегә кайда күпме җыйганнарын исәплибез. Шуннан соң 2023 елга урман культурасы кампаниясе өчен ничә үсенте барлыгы билгеле булачак, – ди ул.

Ә менә Зәй урманчылыгы хезмәткәрләре үзләрендәге орлыкларны санап чыгарган. Аларда 1,5 миллион утырту чималы бар икән.

– Бу үсентеләр саны урманнарны торгызу һәм киләсе елда урман культураларын тулыландыру өчен җитәрлек, – ди Зәй урманчылыгының урманнарны торгызу буенча инженеры Лилия Вәлиева.

Урманчылар кышка әзер, дисәң дә була. Бар эшләре системага салынган. Әмма алар табигатьне яратучы кешеләргә өметләнә. Ни дисәң дә, агачлары утырту, өмәләрдә катнашу өчен актив кешеләр кирәк. Соңгы елларда исә Татарстанда табигатьне яратучылар саны артып тора. Бергәләп агач утырта торган гаиләләр, урамнары белән өмә үткәрүче авыллар бар. Кама Тамагының Антоновка авылына баргач, Ринат Шәйхетдинов белән танышкан идем. Аның үз питомнигы бар. Дуслары белән төрле чаралар уздырып, урман утырталар.

Кукмара районының Кәчимир авылында яшәүче 83 яшьлек Салих Шәрипов күп еллар инде агач утырта. Быел исә бакча артына парк та ясап куйганнар. Элек бу урынга Салих абый 150 төп агач утырткан булган. Парк итеп ясап куйгач, агачлар санын тагын да арттырасы килә, ди ул.

Сүз уңаеннан, узган ел «Урманны саклыйк» бөтенроссия акциясе барышында Татарстанда 594 га мәйданда 1,8 млн данә агач материалы утыртылган иде. Бу акция беренче тапкыр илдә 2019 елда үткәрелде. Өч ел эчендә анда катнашучылар 150 млн төп агач утырткан. Быел бу акция сентябрь ае башында Камчаткада башланып китте. Акциянең максаты – янгыннардан аеруча зыян күргән төбәкләргә ярдәм итеп, 70 миллион төп агач утырту.

Республикада табигатьне саклау акцияләре 2011 елдан бирле үткәрелә. 11 ел эчендә 8,1 мең гектардан артык мәйданда 32,1 млн данә үсентеләр утыртылып, анда катнашучыларның саны 567 мең кешедән артып китте.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КӨЗ КӨНЕ НИНДИ АГАЧ УТЫРТЫРГА?

✓**Груша.** Көзен бу агач урынына тиз ияләнә, күп итеп су сибүне таләп итми.

✓**Алмагач.** Язга кадәр җиргә ияләшеп, тамырын ныгыта.

✓**Слива.** Аны алдан яхшылап әзерләнгән туфракка утыртырга кирәк. Ашлама керткәндә, алдагы җиде елга исәпләп саласы. Туклыклы матдәләр җитмәсә, агач начар үсә яки җимешен аз бирәчәк.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләре һәм статусы турында» һәм «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керүче «Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге белән чиктәш чикләрен һәм «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керүче «Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләренең Казан шәһәре муниципаль берәмлеге белән чиктәш чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.

2 статья

«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләре һәм статусы турында» 2004 елның 15 сентябрендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 8 – 9; 2007, № 12 (II өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (VI өлеш); 2012, № 1; 2014, № 12 (IV өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:



2 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең басу аша кишәрлеге («Фәнни шәһәрчек») чиге «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Яңа Поселок поселогының көньяк чигеннән көньяк-көнчыгышка таба 1,8 км ераклыкта урнашкан 43а кисешү ноктасыннан урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатыш юнәлештә 910 м һәм, агачлык-куаклыкларны күл яры буйлап төньяк-көнбатыш яктан әйләнеп үтеп, 390 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, гомуми юнәлештә 160 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба, 230 м чокырлы һәм коры үзәнле җирләр буйлап, 180 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап яшелчә бакчалары чигенең көньяк почмагына кадәр бара, аннары яшелчә бакчаларының көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 30 м көньяк-көнбатышка таба, 500 м төньяк-көнбатышка таба, юл буе урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 40 м төньяк-көнчыгышка таба, аннары, юл буе урман полосасын кисеп үтеп, Казан – Малмыж автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның чигенә кадәр 60 м төньяк-көнбатышка таба, алга таба Казан – Малмыж автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 910 м төньяк-көнчыгышка таба, аннары, сынык сызык ясап, юл буе урман полосасының көньяк чиген әйләнеп үтә һәм урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Казан – Малмыж автомобиль юлының ФГБНУ «ФЦТРБ-ВНИВИ» керү юлы чигенә кадәр 420 м төньяк-көнчыгыш юнәлештә бара, аннары әлеге автомобиль юлының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 60 м төньяк-көнбатышка таба, Казан – Малмыж автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 12 м төньяк-көнчыгышка таба, аннары Казан – Малмыж автомобиль юлының ФГБНУ «ФЦТРБ-ВНИВИ» керү юлының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап юл буе урман полосасының көньяк-көнчыгыш чигенә кадәр 60 м көньяк-көнчыгышка таба, алга таба юл буе урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 280 м төньяк-көнчыгышка таба, аннары, юл буе урман полосасын ике тапкыр кисеп үтеп, 60 м тар полоса буйлап төньяк-көнбатышка таба, 5 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 60 м көньяк-көнчыгышка таба, алга таба шул ук юнәлештә 920 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 43а кисешү ноктасына кадәр бара.».

3 статья

«Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2007, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2008, № 12 (VI өлеш); 2013, № 5; 2014, № 12 (V өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:



«Биектау муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге составына керүче авыл җирлекләре

Карта-схема буенча №	Муниципаль берәмлек
1	Айбаш авыл җирлеге
2	Алан-Бәксәр авыл җирлеге
3	Әлдермеш авыл җирлеге
4	Каенлык авыл җирлеге
5	Бөреле авыл җирлеге
6	Олы Битаман авыл җирлеге
7	Олы Кавал авыл җирлеге
8	Биектау авыл җирлеге
9	Дачный авыл җирлеге
10	Дөбъяз авыл җирлеге
11	Иске Казан авыл җирлеге
12	Казаклар авыл җирлеге
13	Красносельский авыл җирлеге
14	Коркачык авыл җирлеге
15	Мәмдәл авыл җирлеге
16	Мүлмә авыл җирлеге
17	Алат авыл җирлеге
18	Семиозерка авыл җирлеге
19	Суыксу авыл җирлеге
20	Ташлы Кавал авыл җирлеге
21	Усад авыл җирлеге
22	Чыпчык авыл җирлеге
23	Чернышевка авыл җирлеге
24	Шәпше авыл җирлеге
25	Ямаширмә авыл җирлеге

»;

2) 2 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең чиге «Казан шәһәре» муниципаль берәмлегенең басу аша кишәрлеге («Фәнни шәһәрчек») белән чиктәш җирдә Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Яңа Поселок поселогының көньяк чигеннән көньяк-көнчыгышка таба 1,8 км ераклыкта урнашкан 70 (43а) кисешү ноктасыннан урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатыш юнәлештә 910 м һәм, агачлык-куаклыкларны күл яры буйлап төньяк-көнбатыш яктан әйләнеп үтеп, 390 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, гомуми юнәлештә 160 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба, 230 м чокырлы һәм коры үзәнле җирләр буйлап, 180 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап яшелчә бакчалары чигенең көньяк почмагына кадәр бара, аннары яшелчә бакчаларының көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 30 м көньяк-көнбатышка таба, 500 м төньяк-көнбатышка таба, юл буе урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 40 м төньяк-көнчыгышка таба, аннары, юл буе урман полосасын кисеп үтеп, Казан – Малмыж автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның чигенә кадәр 60 м төньяк-көнбатышка таба, алга таба Казан – Малмыж автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 910 м төньяк-көнчыгышка таба, аннары, сынык сызык ясап, юл буе урман полосасының көньяк чиген әйләнеп үтә һәм урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Казан – Малмыж автомобиль юлының ФГБНУ «ФЦТРБ-ВНИВИ» керү юлы чигенә кадәр 420 м төньяк-көнчыгыш юнәлештә бара, аннары әлеге автомобиль юлының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 60 м төньяк-көнбатышка таба, Казан – Малмыж автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 12 м төньяк-көнчыгышка таба, аннары Казан – Малмыж автомобиль юлының ФГБНУ «ФЦТРБ-ВНИВИ» керү юлының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап юл буе урман полосасының көньяк-көнчыгыш чигенә кадәр 60 м көньяк-көнчыгышка таба, алга таба юл буе урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 280 м төньяк-көнчыгышка таба, аннары, юл буе урман полосасын ике тапкыр кисеп үтеп, 60 м тар полоса буйлап төньяк-көнбатышка таба, 5 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 60 м көньяк-көнчыгышка таба, алга таба шул ук юнәлештә 920 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 43а кисешү ноктасына кадәр уза.»;

3) 10 нчы кушымтага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Биектау авыл җирлегенең чиге «Казан шәһәре» муниципаль берәмлегенең басу аша кишәрлеге («Фәнни шәһәрчек») белән чиктәш җирдә Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Яңа Поселок поселогының көньяк чигеннән көньяк-көнчыгышка таба 1,8 км ераклыкта урнашкан 70 (43а) кисешү ноктасыннан алып Биектау муниципаль районы чиге буйлап 70 (43а) кисешү ноктасына кадәр уза.».

4 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 04 октябрь
№ 60-ТРЗ



«Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 – 2, № 4, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның 1^1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яисә массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйләнеше булган оешмаларның һәм физик затларның БМО Уставының VII бүлеге, БМО Иминлек Советы яисә БМО Иминлек Советы карарлары нигезендә махсус төзелгән органнар тарафыннан каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында төзелә торган исемлекләренә кертелгән зат.»;

2) 11 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яисә массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйләнеше булган оешмаларның һәм физик затларның БМО Уставының VII бүлеге, БМО Иминлек Советы яисә БМО Иминлек Советы карарлары нигезендә махсус төзелгән органнар тарафыннан каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында төзелә торган исемлекләренә кертелгән зат.».

2 статья

Әлеге Закон 2022 елның 1 декабреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 04 октябрь, № 61-ТРЗ

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 3 өлешендә «органнары» сүзеннән соң «озайтылган көн төркемнәре эшчәнлеген,» сүзләрен өстәргә;

2) 4 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы, федераль башкарма хакимиятнең гомуми белем бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм аны гамәлгә ашыру, норматив хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы органы белән килештереп, төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда педагог хезмәткәрләр әзерли торган документларның әлеге федераль орган тарафыннан раслана торган исемлегенә өстәп, мондый документларның өстәмә исемлеген расларга хокуклы.»;

3) 12 статьяда «халыкка күрсәтелә торган белем бирү хезмәтләренең һәркем алырлык булуын һәм» сүзләрен «белемне һәркем алырлык булуын һәм аның» сүзләренә алмаштырырга;

4) 18 статьяда:

а) исемендә «Мәгариф өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне» сүзләрен «Уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруны» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Россия Федерациясендә уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә һәм Федераль законда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.»;

в) 2 өлештә «мәгариф өлкәсендә дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар» сүзләрен «уку-укыту программасын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү күләме» сүзләренә алмаштырырга;

г) 3 өлештә «Мәгариф өлкәсендә дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарга» сүзләрен «Уку-укыту программасын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү күләменә» сүзләренә алмаштырырга;

д) 4 өлештә «мәгариф өлкәсендә дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар шул исәптән белем алучыларның санына бәйле булмаган белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чыгымнарны да күздә тотарга тиеш» сүзләрен «уку-укыту программасын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү күләменә шул исәптән белем алучыларның санына бәйле булмаган белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чыгымнар да керергә тиеш» сүзләренә алмаштырырга;

е) 5 өлештә «мәгариф өлкәсендә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпкә алып» сүзләрен «дәүләт йөкләмәсен яисә муниципаль йөкләмәне үтәүне финанс белән тәэмин итү күләмен билгеләү өчен билгеләнгән тәртипкә охшаган тәртиптә» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 04 октябрь, № 62-ТРЗ

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) унберенче абзацта «берәмлекләрдәге янгыннардан,» сүзләрен «берәмлекләрдәге, федераль территориядәге янгыннардан, ябык административ-территориаль берәмлекләрнең, федераль территорияләрнең» сүзләренә алмаштырырга»;

б) унбишенче абзацта «көчләре белән» сүзләреннән соң «торак пунктларында, шул исәптән шәһәр урманнарында» сүзләрен, «берәмлекләрдәге,» сүзләреннән соң «федераль территориядәге,» сүзләрен өстәргә;

2) 19 статьяның икенче өлешендә «гамәлләреннән» сүзеннән соң «, шулай ук федераль законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә шартлау куркынычы булган предметларны эзләү, зарарсызландыру һәм (яисә) юкка чыгару эшләрен үткәрүдә, халыкара программаларны, проектларны һәм миналардан чистарту буенча гуманитар операцияләрне гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтүдә катнашудан, шартлату эшләрен башкарудан».

2 статья

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 1 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты 2022 елның 13 октябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 04 октябрь, № 63-ТРЗ

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законына (2020 елның 19 ноябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 12; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктына «гамәлгә ашыручы оешма» сүзләреннән соң «(алга таба шулай ук – проектны гамәлгә ашыра торган оешма)» сүзләрен өстәргә;

2) 3 статьяда:

а) 1 өлешнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан гавами проектлау инициативасын формалаштырганда капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкару хакында Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган гомуми таләпләргә туры килә торган декларация рәвешен раслау;»;

б) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 2^1 пункт өстәргә:

«2^1) инвестиция проектын карау һәм дәүләт (муниципаль) ярдәме чараларын куллану максатларында инвестиция проектының Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджеты акчаларын нәтиҗәле куллану критерийларына туры килүе (уңай бәяләмә) яисә туры килмәве (тискәре бәяләмә) турында аңа бәяләмә әзерләү. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, проектны гамәлгә ашыручы оешмадан инвестиция проектын карау турында гариза кергән көннән алып чираттагы эш көненнән дә соңга калмыйча, мондый гариза керү турында социаль-икътисадый үсеш анализы һәм фаразлары өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функциясен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимияте органына Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә хәбәр итә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, проектны гамәлгә ашыручы оешмадан шундый гариза кергән көннән алып 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, инвестиция проектын карый һәм аның нәтиҗәләре турында проектны гамәлгә ашыручы оешмага һәм социаль-икътисадый үсеш анализы һәм фаразлары өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функциясен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимияте органына хәбәр итә. Күрсәтелгән хәбәрнамәләргә инвестиция проектын карау нәтиҗәләре буенча әзерләнгән бәяләмәнең күчермәсе кушымта итеп беркетелә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы билгеләнгән срокларда бәяләмәне проектны гамәлгә ашыручы оешмага һәм социаль-икътисадый үсеш анализы һәм фаразлары өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функциясен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимияте органына җибәрмәсә, йә күрсәтелгән хәбәрнамәгә инвестиция проектына бәяләмәнең күчермәсен кушымта итеп беркетмәсә, инвестиция проекты уңай бәяләмә алган дип санала;»;

3) 6 статьяның 2 өлешендә «социаль-икътисадый» сүзен төшереп калдырырга;

4) 9 статьяда:

а) 1 өлештә:

беренче абзацта «салымны кайтаруны» сүзләреннән соң «(әгәр капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү Россия Федерациясе белән төзелгән булса)» сүзләрен өстәргә;

4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2^1 өлеш өстәргә:

«2^1. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән дәүләт ярдәме чаралары төсле металл (алтын) рудалары чыгару өлкәсендә капитал салулары күләме кимендә 300 миллиард сум булган проектны гамәлгә ашыручы һәм региональ инвестиция проектларында катнашучылар реестрына кертелгән, капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү төзегән оешмага бирелми.»;

в) 5 өлештә:

4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 7^1 пункт өстәргә:

«7^1) салымнар һәм җыемнар өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимияте органының салым контролен үткәргән вакытта проектны гамәлгә ашыручы оешманың әлеге статьяның 1 өлешендә каралган фактта тотылган чыгымнар күләмен бозып күрсәтү фактлары ачыкланмау (ачыклану) турында, шулай ук проектны гамәлгә ашыручы оешмага карата әлеге статьяның 1 өлешендә каралган фактта тотылган чыгымнар күләмен билгеләүнең дөреслеге мәсьәләсе буенча үткәрелгән салым мониторингы кысаларында чыгарылган үтәлмәгән дәлилләнгән фикерләрнең булмавы (булуы) хакында бәяләмәсе бирелгән булса;»;

түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

«10) проектны гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 6 пунктындагы «б» пунктчасында каралган карар кабул ителсә.».

2 статья

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 3 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пункты 2023 елның 11 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай эчендә үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 04 октябрь, № 64-ТРЗ

«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 4^1 пункт өстәргә:

«4^1) Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган методик күрсәтмәләр нигезендә хуҗасыз йорт хайваннарының гражданнарның тормышына яисә сәламәтлегенә зыян китерүләрен булдырмау тәртибен билгеләү;»;

2) түбәндәге эчтәлекле 1^1 өлеш өстәргә:

«1^1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты йорт хайваннарын тотуга, шул исәптән аларны урамда йөртүгә, Федераль законда билгеләнгән таләпләргә өстәмә таләпләр билгеләргә хокуклы.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 04 октябрь, № 65-ТРЗ

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясындагы 1 өлешенең 6^1 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1(I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), «органнарның һәм тукымаларның» сүзләрен «кеше органнарының, сөяк җелегенең һәм гемопоэтик төп күзәнәкләрнең» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 04 октябрь, № 66-ТРЗ

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 1 пунктының беренче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), «салымнар һәм җыемнар» сүзләрен «салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2 статья

Әлеге Закон 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 04 октябрь, № 67-ТРЗ

«Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 1 пунктына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 17 (I өлеш), түбәндәге эчтәлекле «з» пунктчасы өстәп, үзгәреш кертергә:

«з) тимер юл транспорты өлкәсендә табигый монополия субъекты тарафыннан гомуми файдаланудагы тимер юл транспорты инфраструктурасы объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга граждан-хокук шартнамәләре төзелгән юридик затлар гамәлгә ашыра торган шушы эшләрне башкару максатларында кирәкле гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен гомумтаралган файдалы казылмалары булган һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын аукцион үткәрмичә бирү турында;».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 04 октябрь, № 68-ТРЗ

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясындагы 3^1 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 49 (I өлеш), «ике айдан да» сүзләрен «15 эш көненнән дә» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 04 октябрь, № 69-ТРЗ

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 23 сентябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 27 декабрендәге 101-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), «44^5 статьясындагы 3 пунктының,» сүзләреннән соң «53^1 статьясының,» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 04 октябрь, № 70-ТРЗ

Белдерү

Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәр

Түбәндәге территориядә урнашкан күчемсез милек объектларына карата 2022 елның 23 июнендәге килешү нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Алабуга муниципаль районы, Бехтерово авыл җирлеге, Бехтерово авылы, кадастр кварталы номеры 16:18:060301.

Мәнфәгатьле барлык затларга территориянең карта-планы проектын әзерләүнең тәгәлләнүе турында хәбәр итәбез. Аның белән килештерү комиссиясенең эш адресы буенча: Татарстан Республикасы, Алабуга ш., Нефтьчеләр пр., 30 й. (телефон: (85557) 3-82-52) яки түбәндәгеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында танышырга мөмкин:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (Комплекслы кадастр эшләре заказчысының) – https://mzio.tatarstan.ru;

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы хакимиятенең (территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте башкарма органының) – http://городелабуга.рф;

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте Татарстан Республикасы буенча идарәсенең (кадастр учеты органының) – https://rosreestr.tatarstan.ru.

Аларга карата 16:18:060301 кадастр кварталы территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2022 елның 26 октябрендә 13 сәгать 00 минутта түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Алабуга ш., Нефтьчеләр пр., 30 й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2022 елның 6 октябреннән 2022 елның 26 октябренә кадәр һәм 2022 елның 26 октябреннән 2022 елның 29 ноябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә һәм әлеге каршы килүне җибәргән зат турында мәгълүматларны, шул исәптән фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булганда), шулай ук милекче адресын һәм (яки) милекченең электрон почтасы адресын, шәхесен раслаучы документы реквизитларын, җир кишәрлеге чикләренең урнашу урыны белән килешмәве сәбәпләре нигезләнешен, җир кишәрлегенең кадастр номерын (булганда) яки территориянең карта-планы проекты нигезендә җир кишәрлеге билгеләнешен үз эченә ала. Шушы каршы килүне җибәргән затның мондый җир кишәрлегенә хокукын раслаучы документлар күчермәләре яки мондый җир кишәрлегенә хокукны билгеләүче яки раслаучы башка документлары, шулай ук мондый җир кишәрлеген булдырганда чикләрнең урнашу урынын билгеләүче (билгеләгән) документлар (булганда) әлеге каршы килүләргә кушып бирелергә тиеш.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәр

Түбәндәге территориядә урнашкан күчемсез милек объектларына карата 2022 елның 23 июнендәге килешү нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Олы Карагуҗа авыл җирлеге, Олы Карагуҗа авылы, кадастр кварталы номеры 16:20:060102.

Мәнфәгатьле барлык затларга территориянең карта-планы проектын әзерләүнең тәгәлләнүе турында хәбәр итәбез. Аның белән килештерү комиссиясенең эш адресы буенча: Татарстан Республикасы, Зеленодольск ш., Ленин ур., 41а й. (телефон: (8-84371) 4-25-13) яки түбәндәгеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында танышырга мөмкин:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (Комплекслы кадастр эшләре заказчысының) – https://mzio.tatarstan.ru;

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы хакимиятенең (территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте башкарма органының) – https://zelenodolsk.tatarstan.ru;

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте Татарстан Республикасы буенча идарәсенең (кадастр учеты органының) – https://rosreestr.tatarstan.ru.

Аларга карата 16:20:060102 кадастр кварталы территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2022 елның 24 октябрендә 13 сәгать 00 минутта түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Зеленодольск ш., Ленин ур., 41а й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2022 елның 4 октябреннән 2022 елның 24 октябренә кадәр һәм 2022 елның 24 октябреннән 2022 елның 27 ноябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә һәм әлеге каршы килүне җибәргән зат турында мәгълүматларны, шул исәптән фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булганда), шулай ук милекче адресын һәм (яки) милекченең электрон почтасы адресын, шәхесен раслаучы документы реквизитларын, җир кишәрлеге чикләренең урнашу урыны белән килешмәве сәбәпләре нигезләнешен, җир кишәрлегенең кадастр номерын (булганда) яки территориянең карта-планы проекты нигезендә җир кишәрлеге билгеләнешен үз эченә ала. Шушы каршы килүне җибәргән затның мондый җир кишәрлегенә хокукын раслаучы документлар күчермәләре яки мондый җир кишәрлегенә хокукны билгеләүче яки раслаучы башка документлары, шулай ук мондый җир кишәрлеген булдырганда чикләрнең урнашу урынын билгеләүче (билгеләгән) документлар (булганда) әлеге каршы килүләргә кушып бирелергә тиеш.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

КУЯН АРЫСЛАН БУЛА АЛМЫЙ

Мәктәпләрдә бердәм дәреслекләр, программалар буенча укыту турында сүз бара. Шулай ук киләсе уку елыннан астрономия, хокук дәресләре дә мәҗбүри булудан туктаячак. Мәгариф өлкәсендә көтелә торган үзгәрешләр, бүгенге белем бирүдәге хаталар турында Казан инновацион университет проректоры, педагогика фәннәре докторы, профессор Дания ӘХМӘТОВА белән сөйләштек.

:: Дания Заһриевна, киләсе елдан мәктәпләрдә астрономия, икътисад, хокук, экология кебек фәннәрне укыту мәҗбүри булмаячак. Бу дәресләрнең кирәксезгә әйләнүе сездә борчу тудырамы?

– Әлеге фәннәрнең программадан төшеп калуыннан риза түгел. Алар барысы да балада дөньяга караш тәрбияли бит. Балаларга икътисад белеме кирәк. Дөрес, быел мәктәпләрдә финанс белеме дәресләрен укыта башладылар. Анысы яхшы. Астрономияне ничек инде өйрәтмисең ди?! Галәм, планеталар хакында балалар белергә тиеш. Яшел Үзән районында мәктәп директоры булып эшләгәндә, балалар өчен мәктәп планетарием булдырмакчы идем. Кызганыч, проектны ахырга кадәр җиткерә алмадым. Бик авыр гаиләдә үскән балалар бар иде. Әти-әниләре тәртип дигән нәрсәне белмәде. Бер бала урамга чыга да: «Тегеләр бик бай, без фәкыйрь», – дип, тигезсезлектән зарланырга тотына. Шул ярсыган баланы планетарийга алып менеп, аңа телескоптан күкне күрсәтергә хыялланган идем. Галәмдәге үзгәрешләрне күреп, кеше үзе дә үзгәрә бит ул. Бу фән бик кирәк. Хокук дәресләре исә кемгә комачаулаган? 1998 елда Америкада булдым. Анда укучылар көн саен арыш капчыгы кадәр букчаларын күтәреп килеп, һәр көн Америка Конституциясен укый иде. Бала хокукларын да, җаваплылыгын да белергә тиеш. Әгәр дә бу фәнне укытырга укытучыларны әзерләмәгәнбез икән, бу мәгариф өлкәсендәге сәясәтнең дөрес булмавын күрсәтә.

:: Соңгы вакытта «алтын стандартлар», бердәм программа, дәреслекләр булдыру турында сүз бара...

– Минемчә, стандартның 80 проценты гомуми булсын. Калганы – төбәк компоненты. Укучы татар халкының тарихын, мәдәниятен, телен дә белергә тиеш. Үзең торган җирдә яшәп надан булсаң, бер дә дөрес түгел бит инде. Туган җирне, әти-әнине хөрмәт итәргә кирәк. Бездә укыган укытучылар нинди генә төбәктә эшләсә дә, алар укытырга әзер булырга тиеш. Укучылар да тегендә-монда күченеп тора. Кемдер авылдан шәһәргә килсә, кемдер гаиләсе белән Мәскәү, Петербургка күченеп китә. Бердәм дәреслек, программа булганда, яңа мохиттә укыганда кыенлык тумаячак. Шуңа күрә социаль тигезлекне күздә тоткан стандартлар файдага гына булыр дип уйлыйм.

:: Мәктәпләрнең үзебезнең укыту алымнарына әллә ни игътибар итмичә, чит ил методикасына өстенлек бирүенә, охшарга тырышуга ничек карыйсыз?

– Укытучылар хәзер чит ил һәм башка технологияләргә таянып укыта, кызганыч, ә иң кирәклесен, үзебезнең методикаларны яхшы белми. Хәзер яңа велосипед уйлап чыгарырга кирәкми. Классик белем нигезен галимнәр күптән язып калдырган. Тик инновацион система буенча укыган укытучылар аны белми. Лев Выготскийны да ишеткәннәре юк хәтта. «Кем ул?» – дип сорагач, 300дән артык педагогның нибары өчесе генә кул күтәрде. Бездә электән үк проблемага юнәлдерелгән укыту бар. Швециягә баргач: «Россия галимнәрен беләсезме?» – дип сорадым. «Выготский – безнең Алла ул, шуның буенча укытабыз», – диде алар. Минем шуңа исем китте. Ә безнең укытучылар аның хезмәтләрен белми.

Укытучыларның классик педагогика һәм психология буенча белемнәре булырга тиеш. Балаларның яшь үзенчәлеген белеп укытырга кирәк. Хәзер балалар үзгәрде. Психолог Алексей Николаевич Леонтьев: «Әгәр 5 яшьлек бала «мин үзем», дип әйтсә, шунда шәхес башлана», – дип язган. Хәзер 1,5–3 яшьтә дә балалар «мин үзем» дип әйтә. Чит илләргә охшарга тырышырга кирәкми. Безнең илдәге балалар ничек үзгәрә, шуны белү мөһим.

:: Тәрбия темасын да кузгатыйк әле. Йомыкый балалар җәмгыять өчен күпкә куркынычрак, диләр...

– Мәктәпләрдәге атышлар, колумбайнер тиктомалдан килми. Замана мәктәбендә балаларны анализ ясарга, тәнкыйди фикерләргә өйрәтү җитми. Алар проблема алдында югалып кала. Бер-берсе белән аралашырга өйрәтик. Балалар дәрестә бер-берсенең муен чокырына карап утыра. Тәнәфестә кулларында – телефон. Дәрестә балаларны бер-берсен күрерлек итеп утыртырга була. Белем генә түгел, социаль тәрбия дә бик әһәмиятле.

Мәктәпләрдә тәрбия бар, тик ул – формаль. Бу эшне бик яхшы оештыручыларны да беләм. Балалар мәктәптәге тәрбия эшендә катнашырга яратмый. Шуңа күрә бушлай түгәрәкләр оештырып, бөтен баланы да үзе теләгән юнәлешкә җәлеп итү отышлы. Кызыксындыра торган студиясен, түгәрәген дә ясарга мөмкин. Директордан күп нәрсә тора. Хәзер кайбер төбәкләрдә аларны завхозга әйләндереп бетерделәр яки үзләре дә министр, түрәләр әйткәнне генә көтеп утыралар. Һәр баланың күңеле өчен көрәшергә кирәк. Мин моны мәгариф өлкәсендә 57 ел эшләүче белгеч буларак әйтәм.

:: Сез университеттагы инновацион педагогика һәм инклюзив белем бирү фәнни тикшеренүләр институтын да җитәклисез. Бүген күбебез инклюзив белем бирүне авыру балаларны укыту дип күз алдына китерәбез. Бу чыннан да шулаймы?

– Кызганыч, бик күпләр шулай уйлый. Бу алай гына түгел. Ул – барлык балаларның үзенчәлекләрен истә тотып, бертигез белем бирү дигән сүз. Бик сәләтле, шул ук вакытта начар укучы, гаилә хәле авыр булган, төрле фаҗига кичергән, ятим, авыру балалар бар. Һәрберсенә аерым мөнәсәбәт кирәк.

Бер дәресне күзәтәм. Укытучы бик яхшы дип санала, тик 13 парта арасыннан укучыларын гына күрми. «Якынрак килегез, күзләренә карагыз, сөйләшегез», – дим. Югары сыйныфларда инде бар яктан да сәламәт булган балалар бик аз кала. Кайсының умыртка баганасы кәкрәйгән, кайсында – шикәр чире, аз канлылык, йә кайбер укучылар баш авыртудан зарлана. Боларга да игътибар кирәк. Төрле милләт балалары бар. Мәскәүдәге фәнни конференциядә бер укытучы болай дип сөйләгән иде. Ул дәрестә бер укучысына: «Малай, бөтерелмә», – дип кисәтү ясаган. Тегесе җилкәләрен киңәйтеп, үзен горур тотып: «Мин малай түгел, ир!» – дип төзәткән. Чечнядан килгән икән, әлеге халык кечкенәдән үк балаларында патриотик горурлык хисе тәрбияли. Укучыларның барысы белән дә бертөрле сөйләшергә ярамый.

:: Мәгариф өлкәсендә тагын нәрсәләргә игътибарны арттырырга кирәк дип саныйсыз?

– Хәзер бездә көчле һәм уртача мәктәп нәтиҗәләрен чагыштырырга яраталар. Болай эшләү дөрес түгел. Кайдадыр махсус сәләтлеләрне генә җыялар, кайдадыр начар укучылар, авыру балалар, авыр хәлдәге гаиләләрдә тәрбияләнүчеләр дә бар. Аларны бер дәрәҗәгә җиткерү бик авыр. Куян арыслан була алмый инде. Һәр мәктәпне яки баланы үз үсеше белән генә чагыштыру урынлы.

БДИга карата да үз фикерем бар. Бу төр имтихан укучыларны куркыта, алар имтихан бирәсе бар дип, көллиятләргә кача. Укытучыларның гаделлегенә ышанмый торган балалар бар. Андыйлар тестларны сайлап алырга, ышанганнары сынауны укытучыга бирергә мөмкин. Мәктәп өчен БДИ иң зур нәтиҗә дип саныйлар. Моның белән килешмим. Бер танышымның баласы «5ле»гә генә укыса да, математика, физиканы аңламый, репетиторга йөри. Әниләре ай саен – 12 мең, елга 120 мең сум акча түгә. Димәк, БДИ ул мәктәп нәтиҗәсе генә түгел. Һәр укучының, укытучының дәрәҗәсен күтәрергә кирәк. Кайбер балаларның хәтерләре начар, моңа да игътибарны арттырасы иде.

Сәрия МИФТАХОВА

Вәхшигә әйләнмәсен!

Белем һәм тәрбия

Үсмер ни өчен җинаятькә бара? Аның психологик сәламәтлегенә нәрсә йогынты ясый? Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы туры эфирда уздырган «Ата-аналар җыелышы»нда әнә шулар хакында сөйләштеләр.

Җыелышта баланы тәрбияләү, психологик сәламәтлек, балага интернетның йогынтысы, яшүсмерләрнең хокук бозу мәсьәләләре турында фикер алыштылар.

Ярты ел эчендә республикада үсмерләр арасында җинаять кылу очраклары арткан. Татарстанның Премьер-министр урынбасары Ләйлә Фазлыева фикеренчә, бу үсмерләрнең үзенең һәм башка кешенең тормыш кыйммәте булмау проблемасы белән бәйле. «Бу аның үзенә дә тәэсир итә. Яшүсмерләр арасында үз-үзенә кул салу очраклары да шул хакта сөйли», – диде Ләйлә Фазлыева.

Бала ни өчен җинаятькә бара? Татарстан прокуратурасының балигъ булмаганнар һәм яшьләр турындагы законнарның үтәлешен күзәтү бүлеге прокуроры Ахатжон Ишматов әйтүенчә, төп сәбәпләр – ата-ана тарафыннан тиешенчә контроль булмау, балаларның шуклыгы, гаиләнең имин булмавы, социаль куркыныч хәл, балигъ булмаган баланың һәм аның әти-әнисенең хөкем ителүе, җинаятьчелекне романтикалаштыру. «Еш кына баланың тәмәке тартуы, эчүе, дәрес калдыруы, начар компаниягә кереп китүе тирә-юньгә үзенең өстенлеген, текәлеген исбатлау теләгенә бәйле», – ди Ахатжон Ишматов.

Медицина психологы Илгизә Исмәгыйлова фикеренчә, баланың хокук бозуга омтылышы яшь үзенчәлекләреннән дә тора.

– Яшүсмерлек – шәхес формалашуының иң авыр вакыты. Бу этапта бала мөһим процесслар кичерә. Әгәр ул үсмер яшенә кадәр олылар фикеренә колак сала, алар тарафыннан билгеләнә торган кагыйдәләргә буйсына икән, бу чорда инде башкача. Бу этапта балада гормональ һәм баш мие үзгәрешләре актив башлана. Болар балага тәэсир итми калмый, – дип аңлатты ул.

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының участок хезмәткәрләре һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекләр эшчәнлеген оештыру идарәсе җитәкчесе урынбасары Лариса Осипова әйтүенчә, җинаять кылу ихтималы булган категориягә беренче чиратта имин булмаган гаиләләрдә яшәүче балалар эләгә.

– Баланың җинаять кылу ихтималын аның нинди гаиләдә яшәвеннән һәм кем белән аралашуыннан аңлап була. Кайчагында имин гаиләләрдәге балалар да җинаятькә бара. Монысы инде гаҗәпләнү генә түгел, ә шок тудыра, – диде ул.

Әти-әнинең баланы артык кайгыртуы да сәбәп булырга мөмкин.

– Балага барлык нәрсәне дә рөхсәт итәргә ярамый. Әйтик, бала мәктәптә тәртип боза, дәресләрне өзә, иптәшләрен кыерсыта, ди. Аның әти-әнисе мәктәпкә килә, ни булганын аңлап та бетерми, тик баласының хаксыз булуын берничек тә танымый, аның тәртип боза алуына ышанмый. Ул башкаларны гаепли. Шулай ата-ана, укытучылар, сыйныф арасында дошманлык башлана, – ди Ахатжон Ишматов.

Баланың начар компаниягә эләгүен ничек аңларга соң?

Гаиләсе белән аралашмый, гаилә хәлләре белән кызыксынмый, ешрак өйдән чыгып китә, күп вакытын төрле компанияләрдә үткәрә башласа, зарарлы гадәтләре барлыкка килсә, уйланырга урын бар, ди Лариса Осипова. Бала интернет дөньясына кереп чумса да, сак булырга кирәк.

Татарстанның яшьләр эшләре министры урынбасары Алла Кондратьева, сүзләренчә, интернет – ата-ана игътибарыннан качып була торган бердәнбер мохит. Баланың социаль челтәрләрендә ниләр барлыгын күрү өчен, аның белән ышанычлы мөнәсәбәтләр булдырырга кирәк.

Ләйсән САФИНА

ҮЗЕҢ БУЛЫП КАЛ, ЯМЕ!

Түгәрәк

Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла беркөнне: «Абзый, Чаллыга барып кайтмыйбызмы? Рафис Сәлимҗанов җитмешен тутыра. Сез бер тирәдә укыдыгыз да бугай», – диде. «Мин аның иҗатын юньләп белмим дә бит, җитмәсә, тешләрем дә юк, ничек кенә сөйләрмен соң?» – дигән булам. Ркаил, көтмәгәндә: «Тешең булмагач, ашамый утырырсың», – диде. Шаяртырга аңа куш инде, күңелләрендә юмор хисе булмаганнарны язучыга да санамый Ркаил.

Кыяфәте бер карашка шактый җитди тоелган Рафисны да юморист, Рабит Батулла әйтмешли, «йомры телле» язучы дияргә була. Батулла «юмор» дигән сүзне дә татарның «йомры» дигән сүзеннән алынган дип саный. Язганнарым, бәлки, шаярту кебек тә тоелыр, әмма һәр шаярту, йомры сүз астында тирән мәгънә ята бит.

Рафис Сәлимҗановның «Великий язык тюрков» дигән саллы китабы – шуңа бер мисал, дәлил. Бу – әдипнең икенче генә китабы. Әмма, Рафис уены-чыны белән дигәндәй, бик эчкәре кереп киткән, төрки телләрнең, шул исәптән татар теленең нинди бөек, бай тел булуын, башка телләрне баетуга нинди йогынты ясавын мисаллар китерә-китерә раслый алган.

Чаллыда Муса Җәлил исемендәге китапханәдә узган очрашуда Казан кунакларыннан өч халык шагыйре: Ркаил Зәйдулла, Марсель Гали, Газинур Морат, Рафисның якташы Алмаз Хәмзин һәм «ашамый утыручы» абзагыз катнашты.

Бераз гына лирик чигенеш ясыйк әле. Университетта бер чордарак укысак та, Рафисны күргәнем булмады. Дөрес, аны матбугатта чыгып килгән хикәяләре аша белә идем. Хәтта шаян хикәяләре тупланган «Елан мөгезе» дигән китабындагы ике хикәясен концертларда сөйләп тә йөрдем. «Грипп» һәм «Дүртенче Әхмәт» дип атала иде алар. Ул заманда кеше көлдерәм дип, репертуарга билдән түбән мәзәкләр алу юк иде. Яраткан авторларым Гамил Авзал, Фаил Шәфигуллин һәм Рафис Сәлимҗанов булды. Ә язмыш безне узган ел гына очраштырды. Яшел Үзәннең «Волга» шифаханәсендә бергә ял итәргә насыйп булды. «Насыйп булды» дип махсус язам, чөнки моны очраклылык дип санамыйм. Рафис белән яшәешкә, җәмгыять тормышына, илдә-җирдә булган вакыйгаларга карата фикерләребез тәңгәл килгәнгә, Ходай Тәгалә безгә, аймыл булып йөрмәгез, дип әйткәндер кебек тоела.

Инде ничә еллар Язучылар берлеге әгъзасы булып та, нибары ике генә китабы дөнья күрү, бер уйлаганда, Рафисны бик үк бизәми кебек. Әмма, Ркаил Зәйдулла әйтмешли, күпме шигырьләр язган, күпме шагыйрьләребезгә китаплар чыгарырга ярдәм иткән Дәрдемәнднең нибары бер китабы чыккан. Хикмәт санда түгел. Кайбер язучылар, фәлән хәтле китабым чыкты, дип горурланырга ярата.

Искә килеп төште. Алмаз Хәмзин дә «Озак яшисең килсә» дигән китап чыгарган иде. Бик бәләкәй иде ул. Каләмдәшләре аңа: «Китабыңны нигә зуррак итеп чыгармадың?» – дип әйткәләгәннәр. Ә Алмаз: «Кибет киштәләрендә башкаларның китапларына урын күбрәк калсын өчен», – дип, тегеләрнең авызларын яба торган.

Рафис та, китап язам, дип дөнья шаулатып йөрмәде. Дөресен әйткәндә, кайберәүләр татарда андый язучы барын да белеп бетермиләр, ишеткән бар бугай, дип сөйләнәләр. Инде менә белегез. Тыйнак кына Рафисыбыз, Марсель Гали әйтмешли: «Кеше күзенә бик чалынмыйча, тыныч кына йөреп, менә дигән китап язу өчен түл җыеп яткан иткән бит!»

Марсельнең берәр кеше турында егылып китеп мактау сүзләре әйткәнен ишеткәнем юк. Ә менә Рафис Сәлимҗанов иҗатына югары бәя бирүе «үз өендә хуҗаны яманларга ярамый», дию белән һич тә бәйле түгел. Рафисның «Великий язык тюрков» дигән китабы тарих төпкелләрендә казынып язылган. Газинур Морат Рафисны, тел гыйлеменә археология фәнен дә өстәүче, дип бәяләде. Әгәр «археолог» та булмаса, Рафис дөнья халыклары телләре турында бу хәтле мәгълүмат туплый алмаган булыр иде. Аның китабы – гыйльми хезмәт. Рафис аны 2010 елда ук язган булган. Нигә кеше күзеннән яшереп яткандыр, шайтан белсен. Үзе әйтүенчә, баштарак күңелендә икеле-микеле уйлар туган булган. Чөнки язганнары көтелмәгән фикерләргә, татар теленең бөеклеге турында кеше ышанмаслык дәлилләргә бай. Бәлки, үзен милли шовинизмда гаепләүчеләр дә табылыр дип шикләнгәндер. Шуңа күрә, китабын җиңелчә юморга төреп язган. «Чынлап әйтәме бу Рафис, әллә шаяртамы?» – дип баш катырсыннар әле дип уйлагандыр.

Миңа аның китапны рус телендә язуы да сәер тоелды. Югары белемле татар филологы нигә әле үз теленнән ваз кичкән? Бу хакта үзеннән дә сорадым. «Русчаны күбрәк кеше укыр», – дип уйладым диде дә моңсуланып китте әдибебез. Гомер буе милләт кайгысы белән яшәгән егетне аңлап була иде.

Әле Татарстанга мөстәкыйльлек даулап йөргән елларда ук Чаллы тавышы көчлерәк ишетелә иде. Ул чакта төрле листовкалар, милли азатлык таләп итү белән бәйле башка документларны бастырып чыгару бик четерекле эш иде. Милләтпәрвәрләребезгә аяк чалырга теләүчеләр әледән-әле табыла торды. Кискен хәрәкәтләр ясарга хакимият тә шикләнде. Һәм әлеге документлар Рафис Сәлимҗановның шәхси типографиясендә басылып, «КамАЗ» машиналарына төялеп, Казанга, милләттәшләребез яшәгән төрле төбәкләргә озатылды.

Рафис мәйданнарга чыгып күкрәк сукмады, ачлык игълан итмәде, шул ук вакытта үз алымнары белән көрәшүдән дә туктамады. Ул – бүген дә көрәшче. Үз-үзе, дуслары, хәтта гаиләсе белән көрәшә. Мин аның гаиләдә русча сүз кыстырып сөйләшкән кешегә штраф салуына гаҗәпләндем. Бер сүз саен 10 тәңкә түләтә икән. «Ул хәтле үк кирәкмәс иде, чын диктатор икәнсең», – дип сөйләндем. Ә ул елмаеп кына куйды. «Балаларда туган телгә мәхәббәтне әнә шулай уен белән дә тәрбияләп була. Гаиләдә моны җәза бирү дип түгел, ә закон бозган өчен җавап бирү дип кабул итәләр», – диде.

Шунысы кызык: Ркаил Зәйдулла гаиләсендә дә шундый ук «язылмаган закон» яши икән. Тик штраф 10 түгел, ә 1 тәңкә генә, ди. Ркаил шуларны әйтте дә, бер кызык сөйләп куйды. Бер көнне Ркаилнең кечкенә кызы әтисе каршына килеп баскан да: «Менә син штраф түләтәсең, ә «штраф» дигән сүз татарча ничек була соң?» – дип сораган. Ни дип җавап бирергә дә аптыраган Ркаил. Без дә аптырашта калдык. Тиз генә интернетка кереп караган идем, «штраф» немец сүзе икән, хокук бозган өчен законлаштырылган җәза бирү дигәнне аңлата. «Значит, – мәйтәм, – «штраф» рус сүзе булмагач, аның өчен штраф сала алмыйсың». Кайсыбыздыр: «Ә синең «значит»ың өчен салырга була», – дип көлеп куйды. Күңелдә исә телебезнең киләчәге турында борчулы уйлар иде. Рафис, бәлки, «штраф» дигән сүзнең татардан килеп чыккан икәнен дә дәлилләр әле. Бәлки, телебезне саклау һәм үстерүгә кагылышлы яңа законнар, карарлар да кабул ителер.

Инде дустыбызның язучылык һөнәренә, китаплар чыгаруга килгәндә, әдипнең тагын әллә ничә китап нәшер итәрлек кулъязмалары җыелган икән. Ә «Великий язык тюрков» китабын Кавказ республикаларының кайберләрендә кулдан-кулга йөртеп укыйлар дип ишеттем. Ркаил Зәйдулла аны төрек һәм тагын берничә телгә тәрҗемә итәргә кирәк дип саный.

Гөнаһына керәсем килми, бу китапны үзем тулысынча укып чыкмадым әле. Беренчедән, ул сатуда юк икән инде, әмма электрон версиясен укырга була.

Саубуллашыр алдыннан Рафиска: «Бер-ике китап белән генә калма, барыбер Дәрдемәнд була алмассың, безгә Рафислар да кирәк, үзең булып кал, яме», – дидем.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Игелекле гамәл

Җылы күчтәнәч

Азнакай

Өлешчә мобилизация игълан ителгәч, Азнакайның Сәпәй авылында хәрби хезмәткә киткән егетләргә оекбаш, бияләй һәм шарф бәйләр өчен җепләр әзерли башладылар. Аларның бу күркәм гамәленнән район гына түгел, бөтен республикада үрнәк алдылар.

Сәпәй авылы кул осталары эше белән Татарстан Дәүләт Советы депутаты Таһир Һадиев та танышты.

– Авырлыклар безнең халыкны һәрвакыт берләштерә. Элекке гореф-гадәтләрне искә төшереп, мәдәният йортында көн саен бергә җыелып, хәл-әхвәлләр белешеп, изге догалар укып, хөрмәтле хатын-кызларыбыз солдатларыбызга җылы киемнәр әзерли. Әлбәттә, оекбашларны кибеттән дә сатып алып була, әмма күңел җылысы салып бәйләнгәне бөтенләй башка. Азнакай җирлегендә халык бер-берсенә ярдәмчел булуы белән аерылып тора, бүген бу аеруча нык чагыла, – диде Таһир Һадиев.

Ул сәпәйлеләргә изге гамәлләре өчен рәхмәтен белдерде, исәнлек-саулык, иминлек теләде.

– Мактаныр өчен түгел, аз булса да ярдәмебез тисен дип башлаган эш. Кем сарык йоны китерә, кем йон язарга, эрләргә, бәйләм бәйләргә килә. Көн саен эшкә йөргән кебек йөри әби-апалар. Аларга яшьләр дә кушыла, – ди авыл җирлеге башлыгы Фәния Галиева.

Җырлап, догалар укып, чәйләр эчеп, бер-берсе белән аралашып, матур итеп эшли сәпәйлеләр. Йон эрләү – онытылып бара торган һөнәр. Белмәгәннәр белгәннәрдән өйрәнә. Зәбирә апа Хаҗиева – иң оста эрләүчеләрнең берсе.

– Килен булып төшкәч, 23 яшемдә җеп эрләргә өйрәндем. Хәзер дә кулдан төшермим. Тынычландыра, җанга рәхәтлек бирә. Егетләребез исән-сау әйләнеп кайтсыннар, без бәйләгән оекбаш-бияләйләр аларны салкыннарда җылытсын, көч бирсен, – ди ул.

Авыл халкын үзара якынайта торган эш тә бу. Мондый очрашулар, кич утырулар, аралашулар инде онытылып беткән иде бит.

– Райондагы барлык авыл җирлекләрендә дә мондый эш оештырылды. Бүген мең пардан артык оекбаш, бияләй, шарфлар бәйләнде. Эш дәвам итә. Шушы көннәрдә бәйләгән әйберләрне солдатларыбызга юллыйбыз, алар, башкарган эшләребезне ишетеп, рәхмәт сүзләрен җиткерәләр, – ди район хатын-кызлар советы рәисе, «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Эльвира Галиева.

Резеда ШӘРИПОВА

Премьера

«Ак пароход» – әкиятме?

Рәмис Нәҗмиев

Күпме вакыт узгач та җибәрми торган спектакльләр була. Әтнә театрында караган «Ак пароход» әнә шундыйлардан. Табигать баласы турындагы әсәрне табигать балалары сәхнәләштергәнгә шулай килеп чыккандыр ул.

Бу спектакль нәрсә турында? Мөгаен, битарафлык һәм ул китереп чыгарган нәтиҗә – үлем турындадыр. Хәер, Чыңгыз Айтматов әсәрләрендә берничә мәгънә ята, монда да шулай.

Чыңгыз Айтматов әсәренә алынырга кем батырчылык иткән, дисәгез, Башкортстанның яшь режиссеры Илсур Казакбаев.

– «Ак пароход» әсәренә алынгач, бу кайсы театрга күбрәк туры килер икән, дип уйландым. Дөрес, һәр театр теләсә кайсы әсәрне куя ала. Әмма әсәр белән театр гармониядә булганда гына ниндидер үзенчәлек барлыкка килергә мөмкин. Миңа калса, авылда урнашкан профессиональ театр Айтматов фәлсәфәсенә туры килә кебек. Әсәрнең башында ике әкият бәян ителә, ә соңыннан ул әкиятләрнең берсе дә калмый. Дөрес, әкиятне, уйдырма бит ул, дип кабул итәргә мөмкин. Мин аңа халыкның яшерен рәвештә әйтеп калдырган фикерен туплаган әсәр дип карыйм. Әһәмияте буенча риваятьләрдән соң ул – икенче урында. Әкият яшерен мәгънәләре белән кызыклы. «Ак пароход»та бәян ителгән бер әкияттә биредә яшәүче халыкларның Болан анадан аралулары турында сүз бара. Минем өчен Болан ана – гармония символы. Айтматов үз вакытында, шушы гармониянең бер кыйпылчыгы кителсә, бик зур афәт килеп чыгачагы турында кисәтә. Мине, режиссер буларак, бер сорау борчыды: малай елгада батып үлгәннән соң, калган кешеләр белән ни булыр? Шәхсән миңа ул малайның китүе, бизмәндәге чисталыкның, сафлыкның кимүе белән бер. Шулай итеп, Айтматов балалар дөньясы аша безнең зур афәт алдында булуыбыз хакында кисәтә, үзенең эчке борчылуы белән бүлешә, – диде ул.

Әсәр чиста күңелле, самими малай турында. Аңа хәтта исеме белән дә эндәшмиләр. Спектакль дәвамында бу малайның (Рәзилә Шәрифуллина) әнисенең башка кешегә кияүгә чыгып, үз тормышы белән яшәве, әтисенең малай хыялында ак пароходта хезмәт итүе турында беләбез. Малай хыялында шул ак пароходта әтисе белән очраша, аның белән сөйләшүләре турында мең кат күзаллый, бу хакта үзенең сердәшләренә бәян итә. Ә сердәшләре – дәү таш, бабасы бүләк иткән бинокль һәм өр-яңа портфель. Момун карт – малай өчен ата да, ана да, гомумән, иң затлы, иң ышанычлы кеше дә. Тик Момунның зур бер кимчелеге бар: ул карусыз, мыскыл иткәнгә дә, үзе белән санлашмауларына да түзә. Мөгаен, аның менә шушы умырткасызлыгы малайның үлеменә китерәдер дә. Татарстанның атказанган артисты Марат Хәбибуллин аксакал яшендәге картның йомшаклыгын тетрәндерерлек итеп тасвирлап бирде дә инде. Ә Момунның мескенлеге Оразкул (Зиннур Һадиев) янәшәсендә бигрәк тә калку күренә. Урманчы кияү Момунның кызын кысыр дип мыскыллый, «салып» кайткан саен кыйный. Үзенең бәхетсезлеге үчен бабасыннан да, ташландык малайдан да бик оста ала.

Әсәрдә бик үтемле бер мизгел бар. Малайның портфельле булу шатлыгын әбисе, Бикәй апасы (спектакльдә бу рольне Рәзинә Заһидуллина башкара), эшче Сәетәхмәт (Ләйсән Каюмова), Оразкул белән бик бүлешәсе килә. Оразкулдан калганнары битарафлык белән җавап бирсә, Оразкул, каршыма үз малаем йөгереп чыкмады дип, су буена төшеп елый. Спектакльгә бу күренеш кермәгән, әмма малай фаҗигасе менә шушыннан ук башлана кебек.

Малай алдында Момунның абруе югалу исә фаҗигагә бәйле. Юкса бит нәкъ менә шушы бабасы кыргызларны коткарган Болан ана турындагы әкиятне сөйли. Әлеге боланның, кыргызларга үпкәләп, бу җирләрне ташлап китүе хакында җае чыккан саен искәртә. Боланнар бу җирләрдән кешеләр үзләренә ау игълан иткәч кача. Шуннан бирле җирдән кот китте, дип кайгыра бабай. Ә беркөнне боланнар кайта! Ләкин Момун үз куллары белән Болан анага ата. Малай, моны белгәннән соң, бу җирләрдән балык булып, ак пароходка таба йөзеп китәргә карар кыла. Тик бу да – әкият кенә шул. Малай балыкка да әверелми, ак пароходка да барып җитми…

Момунның боланны ни өчен атуын белер өчен генә булса да, бу спектакльне карарга кирәк. Мин исә режиссерның берничә алымына игътибарны юнәлтәм. Дулкыннарны йөгертүче, боланнарны гәүдәләндерүче төркемнең – Зөһрә Мөхәммәтгалиева, Рәсимә Асрутдинова, Алинә Сидеева, Раил Сәлахиев, Фаяз Хөсәеновның – пластикасы соклангыч. Аларның һәр чыгышы спектакльгә ниндидер фильм төсмерен өсти, авторның озын текстларын ялыкмыйча тыңларга мөмкинлек бирә. Спектакльнең азагы якынлашкан саен, геройлар кырыслана, кешелеклелек сыйфатлары саеккан-нан-саега. Моны режиссер геройларның башларын таш балбалларга әверелдереп тасвирлый. Хәер, икейөзле геройлары да ике йөзле Илсурның. Актерлар битлекләр астында сөйли. Вакыт-вакыт битлекләр юкка чыккалап та ала.

Әтнә театры ихласлыгы, динамикасы белән болай да үзенә җәлеп итә иде инде. «Ак пароход»ы белән уйга салды. Без ничә битлек астына яшеренгәнбез? Гомумән, офыкларда ак пароходыбыз бармы әле безнең? Сораулар күп, җаваплары гына юк.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ЗАМАНЧА ДӘВАЛЫЙЛАР

«РАЗУМЕД» МЕДИЦИНА ҮЗӘГЕНЕҢ ЯҢА КЛИНИКАСЫ АЧЫЛДЫ

Кулай бәядән акыллы медицина! Казанда сыйфатлы медицина өчен барлык уңайлыклары булган «Разумед» (Разумная медицина по доступным ценам) медицина үзәгенең девизы бу. Әле күптән түгел яңа клиникалары ачылды. Заманча медицина үзәгенең үзенчәлекләре нидә? Шул сорауга җавап эзләп, без дә «Разумед» белән танышып кайттык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Разумед» күппрофильле клиникалар челтәрен гамәлгә куючы Рәшит Гайнетдинов ачылышта эшләрен ничек башлап җибәрүләрен искә алды. Баксаң, унбиш ел элек сиксән квадрат метрлы фатирны дәвалау бүлеге итүдән башланган икән ул эш. 2009 елда беренче клиника сафка баскан, ә 2011 елда ике йөз квадрат метрлы бинага күчкәннәр.

– Алдык һәм төзеп куйдык кына түгел, без бу максатка озак бардык. Кечкенә клиникадан башладык. Аннан икенчесен, өченчесен, дүртенчесен ачтык. Вакыт узу белән пациентлар күбәя, керем арта башлады. Аны җиһазлауга, биналарны ремонтлауга салып барабыз. Бөтен җирдә тәртип, һәр клиникада да – заманча яңа җиһазлар. Әйтик, бездә срогы ике елдан узган бер генә УЗИ аппараты да юк, – ди Рәшит Гайнетдинов.

Клиниканы җиһазлауга гына да якынча 100 миллион сум акча тотылган. Югары категорияле акушер-гинеколог, профессор Мәдинә Мәҗитова яңа клиниканың үзенчәлекләре турында сөйләде:

– Бүген без бишенче клиникабызны ачабыз. Бу – премиум класслы клиника. Премиум класс дигәндә без, беренче чиратта, җиһазланышны күз алдында тотабыз. Ул бәяләр югары дигәнне аңлатмый. Бездә бәяләр уртача. Клиникабыз «Сәламәтлек һәм озын гомер студиясе» дип тә юкка гына аталмый. Чөнки безнең максат дәвалау гына түгел, профилактикалау да. Бүген бездә максатчан тикшерену программалары эшли, – диде ул.

Клиника югары технологияле җиһазлар белән тәэмин ителгән. Ике операция бүлмәсе бар. Төрле төрдәге һәм авырлыктагы операцияләр ясарга мөмкинлек бирә торган заманча диагностика җиһазлары – аларның горурлыгы. Шуларның берсе – кольпоскопия аппараты. Аны махсус заказ буенча җыйганнар икән. Физиотерапия кабинеты белән дә горурлана алар. Мондый ассортимент бер генә клиникада да юк, ди Мәдинә ханым.

Клиникада балага уза алмауны да дәвалыйлар.

– Бу юнәлеш буенча нәрсә эшләп була, барысын да эшлибез. Гомумән, гинекологиядә нәрсә эшләп була – аның өчен бездә барлык мөмкинлекләр дә бар. Табибларыбызның – үз методикалары. Тиздән ангиограф сатып алырга уйлыйбыз. Аның белән аналыктагы миоманы операциясез дәвалап була, – диде акушер-гинеколог.

Кыскасы, клиникада хатын-кыз сәламәтлегe өчен барысы да каралган. Өстәвенә педиатрия юнәлешен дә лицензияләү турында уйланалар.

Шунысы бар: хатын-кыз сәламәтлеге ул гинекология юнәлеше генә түгел. Яшь барган саен метаболик, гастроэнтерологик үзгәрешләрне дә күзәтеп барырга кирәк. Бу җәһәттән гүзәл затларга эндокринолог, диетолог, гастроэнтеролог, проктолог, флеболог ярдәм итәргә әзер.

– Без – күппрофильле клиника, хатын-кызның матурлыгы һәм сәламәтлегенә бәйле бар нәрсәне колачлыйбыз. Хатын-кызларга гына түгел, ир-атларның сәламәтлегенә дә зур игътибар бирәбез. Хирургия дә көчле бездә, – ди Мәдинә Мәҗитова.

Рәшит Гайнетдинов әйтүенчә, клиникада ярты миллионнан артык пациент исәптә тора. Алга таба үсеш планнары белән дә уртаклашып:

– Тормышка ашырасы планнарыбыз һәм идеяләребез күп әле. Үз лабораториясе булган яңа бина төзи башладык. Аның өчен җиһазлар сатып алдык инде. Икенче катында профилактик кабул итү бүлмәләре оештырырга уйлыйбыз. Укыту үзәге өчен компьютер класслары ясарга да ниятлибез, – диде ул.

Алай гына да түгел, тагын бер үзәк төзергә планлаштыралар. Монысы инде стационарда ятып дәвалану өчен булачак, ди Рәшит Гайнетдинов.

Мәдинә Мәҗитова сүзләренчә, биредә югары квалификацияле табиблар эшли. Аларның һәркайсы – үз юнәлешендә лидер.

– Медицинада яңа технологияләр кулланып эшләүче профессорларыбыз да җитәрлек. Безнең табиблар пациентларны аерым юнәлеш буенча гына түгел, комплекслы дәвалый. Бу яхшы нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә. Безнең өчен иң мөһиме – пациентларыбызның сәламәтлеген ныгыту, гомерне озайту һәм тормыш сыйфатын яхшырту, – диде ул.

Ләйсән САФИНА

Реклама. 18+ Лицензия – Л041-01181-16/00004429 от 22.03.2022

Институт Здоровья и Долголетия
Разумед Premium

Көндезге һәм тәүлек буе эшли торган стационар: гинекология, урология, проктология, кан тамырлары хирургиясе, терапия, кардиология, эндокринология, диетология, физиотерапия һ.б.

● Киров тыкрыгы, 2а ● Фучик урамы, 53а
● Глушко урамы, 15а
● Ямашев проспекты, 54, 1 корпус
● Беломорская ур., 6.

Акция!
«ХАТЫН-КЫЗ СӘЛАМӘТЛЕГЕ»
•гинекологка күренү
•мазок алу
•ультратавыш ярдәмендә тикшерү (УЗИ)

1750 сум

Мәгълүмат өчен:
+7 (843) 205-23-30.

* Акция кысасында кабул итүче табиблар исемлеген телефоннан белешегез. Акция 2022 елның 1 октябреннән 30 декабренә кадәр дәвам итә.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. АЛДАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШҮ СОРАЛА.

ШӘҖӘРӘ

«Ватаным Татарстан» газетасы һәм Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының уртак проекты

КУЛЫННАН КИЛМӘГӘН ЭШ ЮК

Равил Шәйхуллинны Яшел Үзән районының Айдар авылында мичче, төрле көнкүреш техникасын, электр-радио приборларын, сәгатьләрне төзәтүче, тимердән әйберләр ясаучы буларак бик яхшы беләләр. Хәер, Айдарда дип ялгыш әйтәм бугай. Бөтен тирә-якка даны таралган гаилә инде бу.

Каайчагында, бер кешегә талант өелеп бирелгән, нигә шулай икән, дип уйлап та куясың. Төбенә төшә башласаң, сәбәбе бик гади булып чыга: буыннан буынга, нәсел җебенә үрелеп килә торган һөнәрләр бу. Бары тик өзмәскә, югалтмаска гына кирәк.

– Белем 8 класс кына булса да, кулың эш белсә, югалмыйсың икән ул, – ди Равил абый бу җәһәттән. – Беренче хезмәт көннәремне җәйге каникулда башладым. Ат җигеп, урак уручы, көлтә бәйләүче, чүмәлә куючыларга салкын кизләү суы эчертеп йөрдем. Берзаман кул белән иген сугып, көлтә бәйләү матавыклары бетте. Колхозга Сталин комбайны – 1СК үзйөрешле комбайны кайтты, аны «ДТ-54» тракторы тарттырып йөри иде. Үсә төшкәч, бригадирлар эскерт кую, ат белән салам тарттыру кебек зуррак эшләргә дәшә башладылар. Төнлә ат көтүе көтү, сукачы булып эшләүләр – берсе дә калмады.

Равил абый үзенең шәҗәрәсен дә өйрәнгән. Кем нәрсә белән шөгыльләнгән, кайда йөргән – барысын да биш бармагы кебек белә. Бу нәсел авылның тоткасы булган, ягъни үз тырышлыклары белән дөнья корган җир кешеләре алар. Башта ул җиде буын бабасын санап чыкты. Үзе әтисе белән әнисен генә хәтерли. Бабасы Шәйхулла белән Юынчы авылыннан килгән Гөлҗиһан әбисен күрергә насыйп булмый. Әмма уңган кеше булганлыкларын ишетеп үсә. Бабасы җир эшкәртә, игенчелек белән шөгыльләнә. Чәчүлек өчен күп кенә авылдашларының җирен арендага алып тора. Әнә шулай эше алга киткәч, халык арасында көнләшүчеләр дә табыла. Аңа кулак атамасы тагып, мал-мөлкәтен тартып алалар, үзен Себергә сөрәләр. Гаиләсе авылда кала. Сигез баласы була бабасының: Хәлилулла, Кәлимулла, Әхмәдулла, Насыйбулла, Сәтирә, Мөнирә, Мөсәмирә, Гайшәбикә.

Кәлимулла исемлесе төп нигездә кала. Калганнары төрле җирләргә таралыша. Равил абыйның әтисе Хәлилулла да бәхет эзләп читкә китә. Архангельскида такта яру заводында эшли, алтын приискасында эшләп карый. Балык сату эше белән шөгыльләнә, анысын Мурманскидан заказ биреп кайтарта. Ул чагында Айдардан ерак түгел Козловка бистәсендә (бүген ул Чувашия Республикасына керә) пристань була, шуннан ат белән алып кайталар. Тик, Равил абый әйтүенчә, аны сатып, әллә ни файда күрә алмый.

– Әти сугыш башлануга фронтка китә, – дип сөйли ул. – Ленинград блокадасында да була. Сугыш беткәч, авылга әйләнеп кайта. Аның кайтуы үзе өчен дә, колхоз өчен дә файдалы булгандыр дип уйлыйм, чөнки кулыннан килмәгән эше юк иде. Аның үз куллары белән ясаган молотилкасы (иген сугу машинасы) бик ярдәм иткән. Мин дә бик яхшы хәтерлим әле аны. Рамнары агачтан иде, эчке детальләре – тимердән. Аларны махсус үзе сатып алган. Техниканы аерым мотор ярдәмендә хәрәкәткә китерде. Сөт сепараторларын, кул һәм стена сәгатьләрен төзәтеп, тимер эшләрен коеп куя иде. Әтигә ияреп йөреп, үзем дә мич чыгарырга, радиоприборларны төзәтергә өйрәндем.

Хәлилулла абый сугыштан кайткач кына өйләнә. Әрә авылы кызы Гайшәне ала ул. Бер-бер артлы өч бала дөньяга килә. Кызганыч, әниләре генә, бик каты чирләп, иртә дөнья куя.

– Өч баланы тәрбияләү әтигә бер дә җиңел булмагандыр, – дип уйлый Равил абый. – Үзе белән молотилкада бергә эшләгән Разыя исемле кызны алып кайта. Ул безгә үз әниебез кебек булды: какмады, сукмады, ач-ялангач итмәде. Кырыс чагы да булгандыр, әмма дөрес тәрбия бирә белде.

Әнә шул тәрбия дигәннәре дөрес юлдан тайпылмыйча барырга ярдәм иткәндер дә инде балаларга. Армия сафларында, Балтыйк диңгезендә Равил абый өч ел хезмәт итә. 1967 елда, Октябрьнең 50 еллыгы хөрмәтенә Мәскәүдә Җиңү парадында катнашу бәхете елмая. Сайлап алулары да юкка түгел: яхшы хезмәт итү өстенә буй-сын да менә дигән бит. Мавзолейга кереп, бөек юлбашчыбызны күреп чыгарга да вакыт таба. Севастополь, Бакчасарайда йөрергә дә насыйп була. Хәтта Урта диңгездә Сүәеш каналында кизү торырга да туры килә. Армиядән кайткач, нәкъ әтисе кебек шәһәрдә яшәп карарга була. Заводта токарь булып эшли.

– Кулым эшкә ята иде. Ләкин шәһәрне үз итмәдем, – ди ул. – Туган авыл үзенә тартты. Фермада сөт блогында эшләп йөргән чакта Нурия исемле авылдаш кызга күзем төште. Өйләнештек, бер ул, бер кыз үстердек. Хәзер инде оныкларыбыз үсеп килә.

Төп нигез – туганнарны берләштерә торган урын. Бу Шәйхуллиннар гаиләсе өчен дә шулай. Күгештә яшәүче сеңлесе Равилә, Ачасырда төпләнгән тагын бер сеңлесе Әлфинур гаиләләре эзләрен суытмый. Балачакларын сагынып, туганнарын ихтирам итеп киләләр. Бергә җыелган чакта, әлбәттә инде, әти-әни, әби-бабайлар турында сүз кузгала. Балалар кызыксынып тыңлыйлар, ә өлкәннәр, хатирәләр югалмый әле дип, шатланып сөйлиләр. Мондый хикәятләр аерым бер гаиләгә генә түгел, хәтта авылга гына да түгел, ил язмышына кагыла бит.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6715 данә
Гомуми тираж – 15318 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 348

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+